www.madanizhomga.ru

Мәдәни җомга

1995 елның июленнән башлап чыга

№ 7 (1372) 25 февраль 2022 ел

Татарстанда язылу индексы – П2355.

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:
madani_zhomga
madanizhomga
madanizhomga
madanizhomga



6

Алтын Урданың дәвамчыларыннан булган Нугай Урдасы һәм Казан ханлыгы татарлары бер милләт булып, аралашып яши һәм аларны аерып карау дөрес түгел.

12

Уфада яшәп иҗат итүче рәссам Вәкил Шәйхетдинов татарның үз милләте белән горурланырлык шәхесләрен сурәтләгән портретлары өчен дә мактауга лаек.



14

Казандагы "Гаилә" мәчетенең, чыннан да, исеме җисеменә туры килә, дип раслый аның имам-хатыйбы Рөстәм хәзрәт Хәйруллин.



Үз сәфәрен дәвам итә һаман Сәйяр җанлы олпат театр!..

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Мәскәүдә шагыйрь Муса Җәлилнең 116 еллыгына багышланган «Шагыйрь һәм музыка» музыкаль-шигъри фестивальнең гала-концерты узды.

- Татарстан Язучылар берлеге оештырган «Гомер чалымнары» әдәби очрашулар циклының чираттагы кунагы шагыйрь, прозаик, журналист Марат Кәбиров булды.

- Казанда мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләре мөдирләре, тәрбиячеләре һәм методистлары катнашында «Балалар бакчаларында татар телен укытуның заманча, нәтиҗәле ысуллары» дигән семинар узды.

- Удмуртиянең Милли музеенда Ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгына багышланган күргәзмә ачылды.

- Чаллы татар драма театрында рәссам-каллиграф, Истанбул университеты студенты Айзат Минһаҗев күргәзмәсе ачылды.

- «Микулай» фильмын төшерүчеләр төркеме кинокартинаны тәгәлләп бетерү өчен краудфандинг платформасында акча җыя.

- Татарстан Журналистлар берлегендә Флорид Әгъзамов исемендәге «Әгъзамов укулары» халыкара фәнни-гамәли конференциясе үтте.

- 21 февральдә билгеләп үтелгән Халыкара туган тел көне уңаеннан Болгар ислам академиясе уку йортының укытучылары, докторант һәм магистрантлары катнашында Габдулла Тукайның «Туган тел» шигырен укуга нигезләнгән видеоролик чыгарды.

- Төркиядә татарларның Ерак Көнчыгыш илләренә күченүләре турында «Сөембикәнең күз яшьләре: Идел-Урал төркиләренең Көнчыгыш Азиягә күченүләре» дип аталган китап дөнья күрде.

- Ульяновск шәһәренең «Тәүчә» мәдәният сараенда «Татар теле һәм мәдәнияте» көне узды.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Ольга КАЗАКЕВИЧ, галимә, Россия дәүләт гуманитар университетының Лингвистика институты доценты:

«Рус телендә яхшылап сөйләргә өйрәнгәч, бәлки, үз телемдә белгән кадәресен өйрәтермен» дигән фикер бик тирән утыра, аны җимерергә кирәк. Хәзерге «рус теле – төп тел» дигән менталитет белән телне бер буыннан икенче буынга тапшырып булмаячак. Бирегә ата-аналарның, түрәләрнең, мәгариф министрлыгының телләрнең бер-берсенә комачауламавын, киресенчә, ярдәм итүен аңлавы кирәк».

СЫНАМЫШЛАР

27 февральдә аяз булса – көннәр суыта ● Агачларны бәс сарса – суыта ● Кыш салкын килсә, җиләк-җимеш уңа ● Кыш карсыз булса, җәй иген уңмый ● Мартта еш томан төшсә, җәй яңгырлы килә ● Март коры булса – иген уңа, яңгырлы булса – уңмый.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **6 сәгать 44 минутта** чыкты, һәм ул **17 сәгать 09 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **10 сәгать 25 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **31 минутка озынаячак** һәм киләсе җомгада, ягъни **4 мартта 10 сәгать 56 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

25 февраль – актёр, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Роберт Шәрифҗан улы Әбүлмәмбәтовның тууына 80 ел (1942–2002).

27 февраль – язучы, журналист Изаил Харис улы Зариповның тууына 95 ел (1927–1999).

28 февраль – язучы, журналист Мәрди (Мәрдегаләм) Галләм улы Рафиковның тууына 95 ел (1927–2009);

– шагыйрь Ибраһим Шәйдулла улы Нәфыйковка (Биектаулы) 85 яшь (1937);

– журналист, шагыйрь, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Камил Шәмгун улы Сәгъдәтшинга 70 яшь (1952).

1 март – язучы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Ләлә Нәгыйм кызы Сабировага (Гыймадиева) 75 яшь (1947);

– Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнехановка 65 яшь (1957).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Февраль-мартның магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көннәрне исегезгә төшерәбез: 25 февраль, 3 март.**

* * *

Гадәттә, айның соңгы чирегеннән яңа айга кадәр **(24 февраль – 2 март)** организм киңәюгә бара. Мондый көннәрдә юан эчәклекне чистартуга бәйле процедуралар үткәрү файдалы.

Шунысын да онытмагыз: **18 февральдән 29 апрельгә кадәр** бавыр һәм үт куыгы актив булучан. Шушы вакыт аралыгында аларны чистарту һәм дәвалау уңай нәтиҗәләргә китерә.

###ҺИҖРИ БУЕНЧА 1443 ЕЛ

Бүген рәҗәб аеның 24 нче көне

Түбән Камада – әдәби десант

Узган җомга көнне берьюлы ун язучыны Түбән Кама каласына кунакка чакырдылар. Ярты ел чамасы элек Мөслим районы башлыгы булып торган Рамил Муллинны Түбән Камага күчереп куйдылар, ә ул әле туган җирендә үк ел саен әдәбият көннәре уздыруны гадәткә керткән иде, менә шул йоланы хәзер яңа урынында да дәвам итә икән. Сәбәбе дә җитди – Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулланың алтмыш яшьлек юбилее, Рамил Хәмзә улы аны Түбән Камада да билгеләп үтәргә карар кылган.

Берлек рәисе Р.Зәйдулла житәкчелегендә, составына Зиннур Мансуров, Газинур Морат, Вахит Имамов, Ләбиб Лерон, Илсөяр Иксанова, Вакыйф Нуриев, Хәбир Ибраһимов, Факил Сафин, Лилия Гыйбадуллина кергән әдәби десант булып, Түбән Камага юнәлдек. Көндезге унбер тулганда, Г.Тукай исемендәге үзәк китапханә каршында шәһәр башлыгы Р.Муллин үзе каршы алды. Әүвәл шул китапханә залында Ркаил дустыбыз һәм әдәбият сөючеләр арасында очрашу үткәрдpoints. Аннары, нәкъ Мөслимдәге шикелле үк, байтак тарафка сәяхәтләр башланды. Бөек сынчы һәм рәссам Бакый Урманче исемендәге 2 нче татар гимназиясе укучылары да очрашуга ныклап әзерләнгән. Сан ягыннан республикада иң эре саналган гимназиядә 1200 дән артык бала укый, аларга гыйлем бирүче укытучылар саны да 70 тән арта. Гимназия бинасында сәнгать мәктәбе филиалы да эшли, шулай булгач, билгеле инде, иркен фойеда сабыйлар җырлап-биеп тә, музыка коралларында уйнап та каршылады. Аннары аерым сыйныфлар буенча таралдык. Мин фәкыйрегезгә тугызынчы сыйныф туры килгән иде, "Беренче гонорар" атлы тәүге хикәям генә түгел, "Утлы дала", "Тозлы яра" романнары буенча да сорау яудыра-яудыра, тиргә батырдылар. Туган телендә теттереп сөйләшүче балалар белән әңгәмә кору күңелгә май булып ятты, "аһ, барча татар укучылары да шундый булса икән!" – дигән җылы теләк белән саубуллаштык.

Әхсән Фәсхетдинов атлы талантлы рәссамыбыз гомеренең байтак елларын Түбән Кама каласында уздырды, биредә Кызыл Чишмә тирәсен, шәһәрнең байтак мәдәният үзәкләрен һәм мәктәп диварларын бизәүдә катнашты, шушында Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә һәм "Халык рәссамы" дәрәҗәсенә лаек булды. Үзен вафатыннан соң да сагынып яшиләр, Чулман елгасы буендагы Кызыл Чишмә янында аның исемендәге махсус музей төзеп куйганнар. Тыштан караганда бик гади күренсә дә, эче затлы һәм заманча. Музейның беренче катын Әхсән ага яратып иҗат иткән өй, абзар, мунча, җил, урман... ияләренең рәсемнәре, табигый агачтан кисеп алынган Шүрәле сыны, төрле ботак һәм такталардан ясалган ат сурәтләре бизи. Шушында ук рәссам кулы белән ясалган бөек Тукай рәсеме, Әхсән аганың шәхси автопортреты, хәтта бернечә эш коралы һәм ул утырып агач эшләгән эскәмиягә тикле куелган. Ә музейның икенче катында берникадәр вакыт саен яңарып торучы төрле күргәзмәләр үткәрелә, без барган көндә диварларны туган як табигатен сурәтләгән искиткеч матур фотоэтюдлар бизәп тора иде...

Шәһәр үзәгенә кабат кайтышлый балаларның 1 нче сәнгать мәктәбенә кердек. Өч сыйныфта өч төркемнең сәнгати уку дәресләре белән таныштык, укучылар ясаган рәсемнәрне күреп хозурландык. Балаларның һәммәсе дә рәссам яки дизайнер булып китмәс, әмма алар кече яшьтән матурлыкны, нәфислекне, сәнгати зәвыкны "тотып-татып" карарга өйрәнә, аларның һичкайчан җинаять юлына басмаячагына тамчы да шик юк, димәк, барча җәмгыятьнең сафлыгына да үз өлешләрен кертәчәкләр әле...

Ркаил каләмдәшебез юбилеен үткәрү тантанасы Түбән Кама татар дәүләт драма театры коллективына йөкләнгән. Театрның заманча яңартылган бинасын элек тә күргәнебез бар иде. Әмма монда әле узган елда гына кече зал да ясап өлгергәннәр. Әүвәл шул залдагы экран аша һәркайсыбыз өчен таныш булган Әхсән Фәсхетдиновның иҗат эшләрен янә бер кат күздән кичердек. Аннары инде олы залга күчкәч, сәхнә түренә Ркаил Зәйдулланы чакырып чыгардылар. Ркаил Дәүләт Советы депутаты булганчы, шушы театрда әдәби бүлек мөдире булып эшләгән хезмәттәш бит, шуңа күрә әүвәл аны барча коллектив котлады. Шәһәр башлыгы Р.Муллин аңа Рәхмәт хаты тапшырды һәм котлау сүзләрен ирештерде.

(Дәвамы 5 нче биттә).

Классик рәссамыбыз иде

Татарстан җәмәгатьчелеге авыр югалтуга дучар булды. Россиянең атказанган рәссамы, Татарстанның халык рәссамы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Зөфәр Гыймаев 71 яшендә вафат булды.

З.Гыймаев 1951 елда Үзбәкстанның Наманган шәһәрендә туа. 1970 елда Казан сәнгать училищесын тәмамлый, И.Репин исемендәге Ленинград рәсем, сынлы сәнгать һәм архитектура институтында, СССР Сәнгать академиясендә белемен чарлый. 1976 елда Казан сәнгать училищесында укыта башлый. 2008 елда Татарстан Рәссамнар берлеге рәисе итеп сайланып, 2020 елга кадәр шул вазифада эшләде.

Зөфәр Фоат улы Татарстанның әйдәп баручы сынлы сәнгать осталары исәбендә булды. Тематик картина, портрет, пейзаж, натюрморт жанрларында эшләде. Ул – «Әбигә хат килде», «Кечке автобуста», «Өч ай», «Татарстан акробатлары» кебек искиткеч картиналар авторы.

Рәссамның әсәрләре Татарстан дәүләт сынлы сәнгать музее, Красноярскиның В.Суриков исемендәге Сынлы сәнгать музее, С.Сәйдәшев музее, Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында һ.б. да урын алган.

Зөфәр Фоат улы хезмәт сөючәнлеге, кешеләргә ихтирамлы мөнәсәбәте, үз эшенә чиксез тугрылыгы белән аерылып торды.

Халык рәссамы, талантлы шәхеснең якты истәлеге күңелләребездә мәңгегә сакланыр.

Р.Н.МИҢНЕХАНОВ, М.Ш.ШӘЙМИЕВ, Ф.Х.МӨХӘММӘТШИН, А.В.ПЕСОШИН, Ә.Ә.СӘФӘРОВ, В.Г. ШӘЙХРАЗИЕВ, И.Х.ӘЮПОВА, И.Р.МЕТШИН, А.Х.ШИҺАБИЕВ.

Калалар төзегән каләм иясе

22 февральдә язучы, журналист Ягъсуф Шәфыйков вафат булды.

Ягъсуф Долмаган улы Шәфыйков 1937 елның 1 гыйнварында Татарстанның Актаныш районы Түбән Карач авылында колхозчы гаиләсендә туа. 1952 елда гаиләләре белән Удмуртия Республикасының Сарапул шәһәренә күченеп килә. Хәрби хезмәттән кайткач, Сарапул шәһәренең «Красное Прикамье» газетасында бүлек мөдире урынын тәкъдим итәләр. 1970 елда «Удмуртия» нәшриятында «Твои земляки» исемле беренче очерклар җыентыгы дөнья күрә. Читтән торып укып Казан финанс-икътисад институтын тәмамлый.

1972 елда аны КАМАЗ һәм Яр Чаллы шәһәре төзелешенә җибәрәләр. Монда ул профком рәисе, төзелеш оешмасы начальнигы урынбасары булып эшли.

1976 елда «ГлавМосквастрой» оешмасы белән бергә Я.Шәфыйковны Ростов өлкәсенә, Волгодонскидагы атом электр станциясе һәм шәһәр төзелешенә җибәрәләр. 1983 елда бу оешма тагын яңа төзелешкә керешә – Краснодар краендагы атом электр станциясенә нигез сала.

1991 елның декабрендә Я.Шәфыйков яңадан журналистикага, иҗат эшенә әйләнеп кайта. Аны «Татар-информ»ның Төньяк Кавказдагы махсус хәбәрчесе итеп куялар. Аңа Краснодар, Ставрополь крайлары, Адыгей Республикасы, Ростов һәм Волгоград өлкәсендә татар тормышын яктырту бурычы йөкләнә. 1999 елдан башлап әдәби «Татарстан» журналында бүлек редакторы булып эшли. Укучыларга аның «Мин бер могҗиза белән», «Бер очрашу – бер гомер», «Хуш, Агыйдел!», «Калаларда таш казарма», «Фикрят Табеев» китаплары яхшы билгеле.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге

Татарстан Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре узган ел алты томда «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»н әзерләүне төгәлләгән. «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында узган матбугат очрашуында журналистларга аның алтынчы томын тәкъдим иттеләр.

Сөйләм теле һәрдаим үзгәрештә, заманга, дөньяда барган вакыйгалар яки башка сәбәпләр белән ана телебезгә яңа сүзләр килеп керә, кайберләре исә кулланылыштан төшеп тә кала. Галимнәр шуңа күрә дә сүзлекләрнең дә бик тиз искерүен, актуальлеген югалтуын әйтә. 1977-1981 елларда дөнья күргән өч томлык «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» дә, 2005 елда 56 мең сүзне эченә алган бер томлык аңлатмалы сүзлек тә яңартуны сорый иде. Һәм менә 2015 елда Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты лексикография бүлеге хезмәткәрләре алты томлык «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»нең беренчесен эшләп укучы кулына тапшырды. Аннары сүзлекнең ел саен бер томы басыла килде. Әмма алар киң кулланышка чыга алмаган, сүзлекләр белән эшли торган оешмаларга, фәнни учреждениеләргә, китапханәләргә тапшырылып барган.



«Бүгенге көн шартларына туры килерлек яңа аңлатмалар бирүгән мондый академик сүзлек бик кирәк иде. Күп томлы фундаменталь хезмәт элеккерәк елларда чыккан аңлатмалы сүзлекләрдән күләме, эчтәлеге, иллюстратив материалга да бай булуы белән аерыла. Бу томнарда телебездә булган үзгәрешләр теркәлде, искергән сүзләр күрсәтелде, яңа сүзләрнең мәгънәләре ачып бирелде. Бер сүз белән әйткәндә, ул, күләме ягыннан караганда да, сүзлекләрнең иң тулысы», – диде институтның лексикография бүлеге мөдире Ринат Сәфәров.

Өч томлык сүзлектә 36 мең сүз туплап бирелгән булса, алты томлыкка 70 меңгә якын сүз һәм 10 меңнән артык фразеологик берәмлек кертелгән. «Академик алты томлык моңа кадәр дөнья күргән барлык аңлатмалы сүзлекләрнең уңай якларын исәпкә алып төзелде», – диде филология фәннәре кандидаты, өлкән фәнни хезмәткәр Фәридә Таһирова. Әйдәп баручы фәнни хезмәткәр Илһамия Сабитова да сүзлекләрнең бик җентекләп эшләнүен искәртте. «Кайбер сүзләрнең төп мәгънәсен билгеләү өчен бергәләп киңәшергә дә туры килде», – ди ул. 2021 елда сүзлекләрнең алдагы өч томы, Татарстан китап нәшрияты белән килешү нигезендә басылып, китап кибетенә чыгарылган. Алты томлыкның электрон варианты Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының рәсми сайтындагы TATZET платформасында тәкъдим ителә.

С. КЫЯМОВА.

Җидегән
вакыйгалар
хәбәрләр
яңалыклар

АДЫМНАР ЫШАНЫЧЛЫ БУЛСЫН!

Илдә Төп Законга каршы килеп үткәрелә торган милли сәясәт нәтиҗәсендә куркыныч туган телләр һәм милли мәгариф кризисы (ә 2017 елда Йошкар-Олада туган телләрне чикләү буенча Россия президенты катнашында үткәрелгән чарадан соң ул инде бөтенләй дә фаҗигале төс алды, бу өлкәдә законсыз нормалар кабул ителүенә, Татарстанда татар теленең мәктәпләрдән хәтта көч структуралары кулланып куылуына китерде, Удмуртиядә исә милләтпәрвәр-галим А.Разинның, мондый хокуксызлыкларга протест йөзеннән һәм җәмәгатьчелек игътибарын да җәлеп итү ниятендә, 2019 елның 10 сентябрендә парламент каршында чарасызлыктан үз-үзен ут төртеп яндыруына кадәр дә барып җитте), соңгы елларда бераз тоныкланган кебек күренсә дә, проблема беркая да китмәде, ә милләтләр күңелендәге тирән яра вә әчке нәфрәт булып, котылгысыз тәстә үзенең чишелешен көтә. Кызганыч ки, илдә тормыш әлегә үзенең деструктив агышында бара, димәк, туган тел һәм милли мәгариф мәсьәләләрен дә һәр халык үзе, кулыннан килгәнчә хәл итәргә тиеш була. Әйтик, Татарстанда һәм Башкортстанда бу эштә әлегә төп юнәлеш булып полилингваль мәктәпләрне гамәлгә кую тора. Асылда, полилингваль мәктәп ул тәрбия һәм белем бирүне (фәннәрне укытуны) ким дигәндә 3 телдә алып баруны күздә тота. Татарстанда инде икенче ел «Адымнар» дигән андый берничә (тиздән аларның саны алтыга җитәр дип көтелә) мәктәп эшли. Ә аларда тәрбия һәм белем бирү эшләре бүген ни дәрәҗәдә соң?

Куелган сорауга төпле җавап табу өчен, сүзебезне Казандагы «Адымнар» комплексы мисалында алып барырбыз. Мәктәпнең PR-хезмәте хәбәренә караганда, бу ике елда бирердә укучыларның нибары 27 проценты – полилингваль, 64 проценты – билингваль һәм 9 проценты монолингваль юнәлештә аң-белем ала икән. Ә фәннәрне татар һәм инглиз телләрендә дә укыту бары тик беренчесендә генә каралган. Әмма «Адымнар» бит бүгенге кыен хәлдән чыгу максатында, туган телдә тәрбия һәм белем бирүне яңа нигездә җайга салу өчен булдырылган иде. Яңа уку елы алдыннан моны республика җитәкчелеге һәм мәктәп директоры да вәгъдә итте. Әлбәттә, фәннәрне татар һәм инглиз телләрендә дә укыту өчен бу телләрне камил белү мәслихәт һәм моңа ике ел эчендә генә ирешеп булмый. Әмма быелгы 1 нче сыйныф балаларыннан (20 класстан), һич югы 5-6 сыйныфны ике телне дә белә торган балалардан формалаштырырга һәм тәрбия вә белем бирүне татар һәм рус телләрендә башлап җибәрергә, бер үк вакытта татар һәм инглиз телләренә өйрәтүне интенсив исуллларга күчерергә була бит. Бу инде алга таба барлык классларны да полилингваль итү мөмкинлеге бирер иде. Ә бүген эшләр ничек тора соң? Бактың исә, «билингваль» дигәнендә дә, монолингвалендә дә укыту рус телендә генә бара. Аерма бары тик беренчесендә татар теленең атнага 2 сәгать дәүләт теле булара та укытылуында гына. Һәм мондый хәлне әлегә дә баягы ата-аналар теләге белән аңлаталар.

Әмма бу дөрес түгел. Чөнки мәктәп башта ук полилингваль булып төзелде һәм ата-аналар анда балаларын моны белеп бирде. «Прописка» буенча алу да сылтау була алмый. «Адымнар» Казанда ике бинада (Бичурин һәм Бондаренко урамнарында) урнашкан. Минем бер оныгым яңа бинада 3 нче сыйныфта укый һәм анда хәлләр ярыйсы. Икенчесе исә – «прописка» буенча Бичурин урамында, беренче сыйныфта. Ә анда 1 нче класслар саны – 14. Тик берсендә дә ике телне дә белә торган балалар тупланмаган. Шуңа күрә тәрбия һәм фәннәрне укыту рус телендә генә бара. Татар теленең полилингваль мәктәпләрдәге мондый торышын күптән түгел Татарстан президенты да тәнкыйтьләде. Әйе, чыннан да, бүген кылны кырыкка ярырдай чак. Бер караганда, мәктәп җитәкчелеге тырыша да кебек: ата-ана һәм балаларны туган телгә тарту ниятендә артистларны җәлеп итә, башка исул вә мөмкинлекләр эзли. Тик андый чаралар әдәп, әхлак һәм кабул ителеше ягыннан ныклап әзерләнергә, күләме белән дә баланы ялыктырмаска тиеш. Аң-белем бирүдә милләтнең читкә кагылган резервларын (әйтик, шул ук татар теле укытучыларын конкурс нигезендә һәм лаеклы әҗер белән) да җәлеп итү мәслихәт. Кыскасы, теләк булганда, мөмкинлекләрне табып була. Иң мөһиме – «Адымнар» мәктәбен ныклап гамәлгә кертүдәге эшләребез генә түгел, туган телебезне киләчәк теле итүдәге адымнарыбыз да ышанычлы булсын иде.

Фоат УРАЗАЙ.

1 нче биттә – Г.Камал театрының яңа бинасы конкурсында җиңү яулаган бина рәсеме.

Җәлил-Илһам көннәре

Каһарман шагыйрь Муса Җәлил һәм мәшһүр җырчы Илһам Шакировның туган көннәре уңаеннан аларга багышланган атналык узды.

Бу көннәрдә радиолардан бөек шәхесләребезнең җырлары һәм шигырьләре яңгырап торды, мәктәпләрдә, балалар бакчаларында, мәдәният йортларында, китапханәләрдә кичәләр, шигырь-җыр бәйрәмнәре үтте. Муса Җәлилнең тууына 116 ел тулуны билгеләп үткән көннәрдә Казан федераль университетының Г.Тукай исемендәге Милли мәдәният һәм мәгариф югары мәктәбендә дә патриот шагыйрьнең кызы Чулпан ханым белән очрашу уңаеннан “Исемең калсын, үзең үлсәң дә, Тарихларда укып ятларлык” дигән шигърият бәйрәме узды. Ул Сәйдә Мөхәммәтҗанованың видеоэзма аша “Җырларым”ны башкаруы белән башланды. Кунакларны мәктәпнең ректоры Рамил Мирзаһитов сәламләде. Ул республикада Җәлилнең туган көненә багышланган күп кенә чаралар узуын әйтеп, Казанның “Чулпан” мәдәният сараенда М.Җәлил укуларының йомгаклау концерты булуы турында сөйләде. Конкурс барышында каһарман шагыйрь шигырьләрен 48 мең кеше укыган. Алар - Татарстан районнарында, Россия төбәкләрендә һәм чит илләрдә яшәүче төрле яшьтәге кешеләр. Университет ишек алдында 2016 елда ачылган Җәлил бюстына чәчәкләр кую тантанасы да дулкынландыргыч мохиттә узган. Уку йортында студентлар Җәлил иҗатын өйрәнә, чыгарылыш-квалификация, диплом, курс эшләре яза. Ел саен Җәлилгә багышланган кичәләр, шәхесләр белән очрашулар үтә. Бу көнне дә Җәлил шигырьләренә язылган җырларны Гөлзадә Сафиуллина һәм Миңгол Галиев башкарды, студентлар патриот шагыйрьнең шигырьләрен сөйләде. М.Җәлил исемендәге бүләк иясе Гөлзадә Сафиуллинаның шагыйрьнең “Дуска” дигән шигырен укып, мәшһүр шәхесләребезгә багышланган атналыкта алып барылган кайбер эшләр белән таныштырды. Гөлзадә Сафиуллина үзенә Новосибирскидан, Владивостоктан, Урал арьягы шәһәрләреннән, Кырымнан М.Җәлил шигырьләрен сөйләп, Илһам Шакиров җырларын башкарып искә алу кичәләре үтүе турында хәбәрләр килүен сөйләде. Мәчетләребездә Бөек Ватан сугышында башларын салган каһарманнарга, шәһит киткәннәрнең рухына Коръән укыганнар. Татарстан Язучылар берлегендә дә атналык кысаларында әдәби-музыкаль кичә узган, язучылар, шагыйрьләр шигырьләр укып, танылган артистларыбыз Җәлил шигырьләренә язылган көйләрне, Илһам Шакиров башкарган җырларны яңгыраткан, истәлекләр дә барланган. М.Җәлил музей-фатирында М.Җәлил премиясе лауреатлары белән очрашу да хатирә яңартулар белән үрелеп барган. Дин галимнәре, язучылар, дин әһелләре бергәләп, догалар кылып, шәхесләребезне искә алган. Радио фондында 1966 елда татар артистларының 40 минут дәвамында Җәлил шигырьләрен укуы яздырылган аудиотасма табылган, ул да дөньяның төрле илләрендәге татар оешмаларына җибәрелгән.

Җәлилнең кызы Чулпан ханымның әтисе турындагы истәлекләре дә күңелләрдә уелып калды. Гаилә Мәскәүдән Казанга 1939 елда кайта, Җәлил Татарстан Язучылар берлеге җитәкчесе була. Кечкенә Чулпан һәрвакыт әтисе белән бергә. Әтисе Муса Чулпанны Бауман урамындагы Язучылар берлегенә дә, театрга да, үзе язган “Алтынчәч” операсы репетицияләренә дә үзе белән ала. Кызчыкның гаҗәеп бәхетле балачагы сугыш башлану белән тәмамлана.

Әминә ханым һәм Чулпан блокнотны тапшырган Андре Тиммерманс белән бик дус була, Бельгиягә дә баралар. Ул Казанга беренче тапкыр килгәч, Н.Җиһанов язган “Муса Җәлил” операсын да карый. “А.Тиммерманс әти белән бер камерада утырган. Ул әтинең батыр йөрәкле ир-егет булуы турында сөйләде. Андре дәфтәрне 1947 елда тапшыруын, озак вакыттан соң табылуын аңлый алмый иде. Әмма блокнотларның илгә кайтып ирешүе зур могҗиза”, – диде Чулпан ханым. М.Җәлил якын дусты Гази Кашшафка мирасын васыять итә. Язучының дустының исемен аклау өчен бик күп эшләвен беләбез. Чулпан ханым аңа һәм әзләнеп әсәрләр язган Рафаэль Мостафинга бик рәхмәтле.

Очрашуда филология фәннәре кандидаты Миләүшә Хәбетдинова Язучылар берлеге җитәкчесе М.Җәлил, иҗатының чәчәк аткан чоры булган Гадел Кутуй кебек татар язучыларының, броньнән файдаланмыйча, фронтка, алгы сызыкка китүләре, әмма шул ук вакытта күп кенә рус әдипләренең Чистайга эвакуацияләнүе кебек хәлне дә искә төшерде. Галимәне шулай ук М.Җәлил исемендәге дәүләт опера һәм балет театрының патриот шагыйрьнең туган көннәренә битараф булуы, анда Җәлил әсәрләре куелмау мәсьәләсен дә күтәрде. “Анда көннәр дәвамында Җәлил әсәрләре баруы мәслихәт. Шагыйрь тормышыннан музыка китәргә тиеш түгел”, – ди галимә. Аны шулай ук Җәлил һәйкәленә чәчәкләр кую тантанасының гадәтигә әверелә баруы да борчый. “Тантананың һәр минуты алдан уйланылуы кирәк. Анда регламент сакланырга, дәрәҗәле вазыйфаи затлар катнашуы мәҗбүри булырга тиеш”, – ди ул.

Сөембикә КАШАПОВА.

Автор фотолары.

Тарихны өйрәнү милләтне берләштерә

Бөтендөнья татар конгрессы бинасында «Татар төбәк тарихын өйрәнү: 2021 елда Татарстанның һәм Россия Федерациясендә татарлар күпләп яшәгән төбәкләренең тарихларын өйрәнү структуралары эшчәнлеге нәтиҗәләре һәм 2022 елга планнар» дигән темага Бөтенроссия түгәрәк өстәл-конференциясе узды.

Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы, Бөтендөнья татар конгрессының оештырылуына 30 ел тулу, шулай ук Россиядә Халык сәнгате һәм Матди булмаган мәдәни мирасны саклау елы кысаларында үткән эшлекле җыен оффлайн һәм онлайн форматта алып барылды. Конференцияне Конгрессның Татар төбәкчеләре белән эшләү комитеты җитәкчесе Альберт Борһанов алып барды.

2021 ел туган як тарихларын өйрәнүчеләр өчен аеруча уңышлы булуы белән истә калды. Алар авыл-бистә тарихларын ачыклауны фәнни-гамәли конференцияләрдә, форумнарда очрашып, алып барды. Татар төбәкчеләре комитеты оештыруында узган алты җыенның икесе Татарстан җирлегендә, дүртесе илнең башка төбәкләрдә үтте. Зур форумнарның берсе Уфа шәһәрендә узды. Бу фәнни-гамәли конференциядә 18 төбәктән 220 төбәкне өйрәнүче һәм тарихчы галим катнашты, 130 доклад тыңланды. 4-10 сентябрьдә Омск, Тара шәһәрләрендә һәм Свердловск өлкәсендә узган фәнни-гамәли конференция исә үзенә Россиянең 22 төбәгеннән 480 төбәкне өйрәнүчене җыйды. Форумнарда ясалган чыгышлар исә җыентыкларда дөнья күрә. Җыеннар, әлбәттә, үзара аралашу, киңәшү өчен зур форсат булу белән бергә, татарлар күпләп яши торган җирлекләрне күреп, андагы милләттәшләребезгә, татар тарихына бәйле хивларда утырып, тарихи сәхифәләрне барлап әзерләгән 382 китап укучылар кулына килеп ирешкән. Бу басмаларның кайберләре туган яклары тарихын өйрәнүчеләренең үз акчасына, бериш е иганә ярдәме белән нәшер ителгән.

Татарстан Фәннәр академиясе академигы Индус Таһиров төбәкне өйрәнүчеләрнең эшчәнлеген югары бәяләде. Ул әнә шулар ярдәмендә татарлар укмашып яшәгән төбәкләрнең тарихы өйрәнелүен, күп эшләр башкарылуын әйтте. Галим шулай ук дөньяның төрле кыйтгаларына Россия шәһәр-авылларына таралып яшәүче татарлар өчен үзара аралашу кирәк булуын искәртте. Галим шулай ук бүгенге көндә милләттәшләребезнең уянуын, үзебезне бары тик без үзебез генә яклый алуыбызны аңлавын әйтте. Татарларның яшәү рәвешен мари, удмурт, чуаш кебек башка халыклар да үзләренә өлге итә. Аңлашып, бер-беребезгә ярдәм итеп яшәү безнең өчен иң әһәмиятлесе.

Эшлекле җыенда 2021 елда үткәрелгән «Авыл җирлегендәге иң яхшы туган якны өйрәнү музее» дигән Беренче Бөтенроссия конкурсына да йомгак ясалды. Бәйгедә катнашу өчен 23 музей үз проектларын тәкъдим иткән. Аларның эшчәнлеген өйрәнгәннән соң, 13 проект кабул ителгән. Бу музейлар арасыннан җиңүчеләр һәм призлы урыннарны алучылар тәгаенләнде. Конкурсның төп җиңүчесе итеп “Борынгы Чаллы төбәгенә караган шәхси музей” иң яхшы музей дип табылган. Аны язучы, тарих фәннәре кандидаты, дистәләгән тарихи китаплар авторы Нурулла Гарифның Балык Бистәсе районы Яңа Сала авылында үзенең бабалары салган ике катлы йортта корган. Моннан тыш “Төбәк табигате музее”, “Авыл тарихы музее”, “Тематик музей” (археологик, этнографик,хәрби-тарихи һ.б.), “Мәктәптә туган якны өйрәнү музее” дигән номинацияләрдә

истәлекләр белән танышып кайту да. Моннан тыш соңгы елларда Россиянең милләттәшләребез күпләп яшәгән төбәкләрендә, Татарстан район-авылларында халкыбызның, туган җирләренең тарихын өйрәнүчеләр саны елдан-ел арта бара. Хәзер Россиядә татар төбәк тарихын өйрәнүчеләрнең 103 төркеме булуы билгеле. Аларның исәбе елдан-ел арта. Татарстанның үзендә генә дә үз туган якларын өйрәнүчеләрнең 42 төркеме эшчәнлек алып бара. Кайбер районнарда аларның саны алтыга җитә, әмма шул ук вакытта бериш район-авылларда үз яклары тарихын өйрәнүчеләр юк, диярлек.

Төбәк тарихын өйрәнүчеләр арасында фәнни эшчәнлек алып баручылар булуы да күңелле. Алар Татарстан Фәннәр академиясе галимнәре белән берлектә төрле конференцияләрдә дә фикер алышуларда катнаша. Төбәк тарихын өйрәнүчеләрнең еллар дәвамында алып барган эшчәнлеге нәтиҗәсе буларак китаплар дөнья күрә. Соңгы ике елда гына төбәкчеләр, ар-

дә җиңүчеләр тәгаенләнде. Кемерово өлкәсендәге Яшкино районындагы «Калмаки» – Константиновлар юртасы» экологик музей-мәдәни үзәге (авторы – Яшкино мөселман оешмасы рәисе Нәфисә Еремейкина), Башкортстанның Туймазы районы Имангол авылындагы “Туган йорт” музей-комплексы (авторы – төбәкне өйрәнүче, шәхси музей директоры Рафаил Бәхтияров), Самара өлкәсенең Камышлы районы Рус Байтуганы авылындагы «С.Г. Вәгыйзов музей-йорты» (авторы – төбәкне өйрәнүче, музей-йорт мөдире Нурания Абзалова), Пенза өлкәсе Каменка районындагы «Мирас» (авторы – төбәкне өйрәнүче Галия Тенишева), Омск өлкәсе Тара районы Междуречье бистәсендәге “Бистә тарихын һәм традицияләрен саклауда туган якны өйрәнү музее” (авторы – гомум белем бирү мәктәбенең тарих укытучысы Венера Мөхәммәдиева) музейлары тәкъдим иткән проектлар беренче урыннарга лаек булган.

Сөембикә КЫЯМОВА.

Түбән Камада –әдәби десант

(Ахыры. Башы 2 нче биттә).

Бераздан инде сәхнәне Ркаилнең “Нәгыймә” (атаклы Чыңгыз Айтматовның әнисенә багышланган) һәм Л.Толстойның юбиляр тарафыннан татарчага тәрҗемә ителгән “Холстомер” спектакльләреннән өзекләр биләп алды. “Безнең килен кияү күргәнмени”, дигән төсле, күпчелек кунакның сәхнәдә атлар булып уйнаучы артистларны да тәүге тапкыр тамаша кылуы, шуңадырмы тын алырга да куркып күзәттеләр.

Кичәнең режиссеры һәм алып баручысы Рөстәм Галиев, билгеле ки, Казан кунакларын да сәхнәгә чакырды. Уныбыз да сөйләп вакыт сузмыйча, сүзне З.Мансуров белән Ркаилнең сабакташы Г.Морат кына алды, янә бер сабакташы – Л.Лерон юбилярга папаха бүләк итте. Мин фәкыйрегез күңелемнән генә соңгы айлар буе җанымны телгәләгән сүзләрне кабатладым.

“Ркаилнең биш ел буе уйнал-ган “Үлеп яратты” драмасын да сәхнә түреннән тибеп төшерделәр. Татарның мәгърифәтлек буенча “өлкән агай”ның борынына чиертеп яшәве очлы күзле карчыгалар күңеленә ярамады. Спектакльнең төп геройлары булган бертуган Мөхлиса, Гобәйдулла һәм Габдулла Нигъмәтуллиннар гаиләсе 1900 еллар башында татар дөньясының иң караңгы почмагы саналган Иж-Буби авылында Петербургтагы дошманнарның да эчен яндырырдай мәдрәсә төзеп куйсын әле. Татар дөньясының иң күренекле 60 мулласы кул куеп, әлеге мәдрәсәне Уфа каласына күчерүне һәм аңа университет дәрәҗәсен бирүне үтенеп, власть ияләренә мөрәҗәгать юллаган. Ләкин ирек бирү урынына 28 жандарм җыелып килеп, 1911 елның 31 гыйнварында Иж-Буби мәдрәсәсе шәкертләрен куып тараткан, мөгаллимнәрен Сарапул төрмәсенә илтеп япкан, төрек укытучыларын үз ватаннарына куып җибәргәннәр. Бер гасыр вакыт узуга, татар милләтенә һөҗүм янә кабатланды.

Барча Рәсәй мәгарифенә үрнәк булып эшләгән төрек-татар гимназияләрен яптылар, мөгаллимнәрен шымчылыкта гаепләп Төркиягә сөрделәр. Унбиш ел буена татар тарихы бөтенләй укытылмый, дүрт ел элек кирза итекләләр татар телен дә идәннәргә салып, таптап чыкты. 68 яшьлек хатынны төрмә диварына терәп юк итүне Җир шарының күргәне юк иде, ике көн элек кенә, тарихта бердәнбер итеп, шул ук кара көчләр Олимпия чемпионы исемен дәгъвалаучы 15 яшьлек татар кызын таптап юк итмәкче булды. Татарны биш гасыр буе изеп яшәүгә протест итеп, “Үлеп яратты”ны сәхнә түреннән төшермәскә иде дә бит, тарих кабатлана, ул тегермән гел татарны тарта...”

Ходайның рәхмәте белән Казаннан Азат Тимершәех һәм Рөстәм Маликов безгә сәфәрдәш булып килгән иде. Кичә барышында Азат юбилярның сүзләренә язылган ике җырны, ә Рөстәм әфәнде үз җырын курай һәм кубыз моңнары белән аралаштырып шаккатырды. Юлчыларны белеп сайлаганнар, кайткан чакта сузган күмәк җыр моңнары юл читендәге агач башларына, тимерчыбыктан корылган нота станнарына да уралып калды әле.

И.ВАХИТОВ.
Л.ЛЕРОН фотолары.

Казан татарлары, нугай һәм башкортлар

XV гасырда Алтын Урдада үзгәрешләр нәтиҗәсендә, берничә татар дәүләте, шул исәптән, Нугай Урдасы һәм Казан ханлыгы барлыкка килә.

Рус этнографлары билгеләмәсе буенча, Нугай Урдасы татарлары борынгы заманнарда ук башкалар белән чагыштырганда иң затлысы исәпләнгән. Аларның биләмәләренә көнбатышта Дунай елгасы яны һәм Кырым ярымутравы, ә көнчыгышта Җаек елгасы бассейннары булып, бу ике арада булган зур җирләр кергән. Бөек Нугай Урдасының бу биләмәләрендә күпләгән зур һәм кече урдалар төзелеп, аларда күп санлы татар халыклары яшәгән. Аларның бер өлеше күчмә тормышта – юрталарда (һәм кибиткаларда), башкалары өйләр салып, авыллар булып гомер иткән.

Болгар чорының мәдәнияттен, сәүдә, фән һәм башка утрак тормыш казанышларын үзенә алган Казан ханлыгы татарлары һәм дала культурасын, хәрби тормыш үзенчәлекләрен үзенә сеңдергән, аларның дәүләтчелек башында торган Мангыт кабиләсенең бөек шәхесләре булган Нугай Урдасы татарлары арасында ныклы рухи бәйләнешләр урнаша.

XV-XVI гасырларда бу ике тугандаш халык бер-берсен тулыландырып, бербөтен татар халкы булып формалаша һәм киләчәк язмышлары аерылгысыз булып, бүгенге көндә татар милләтенең рухи һәм мәдәни үзәгенә әверелә. Рус тарихчылары да «ике дәүләтнең шактый җирләре бергә идарә ителә», – дип күрсәтә. Хәрби яктан бик көчле булган Нугай Урдасы татарлары Казан ханлыгының саклаучылары да булып санала.

1552 елда рус патшасы Иван IV Казанны басып ала. «Казан патшалыгы тарихы» китабында Казанның халкы тулысы белән юк ителгәне әйтелә. Казан татарлары белән бергә Нугай Урдасы татарлары Казан ханлыгын саклап, бик күпләре һәлак булган. «Нугай Капкасы янында 36 мең нугай татарының гәүдәләре күмелми ятканы» язып калдырылган. Бу корбаннар Рус гаскәрләре ягында сугышкан татарлар – Шаһ Гали һәм Камай морза вөҗданында да. Алар ханлыкны җимерүдә һәм халкын һәлак итүдә катнаша. Бу тарихыбызда, татарларның татарларны һәлак иткән иң авыр сәхифә, Казан ханлыгы юк ителү, анда яшәгән татар халкы һәм башка халыклар тормышына килгән афәт, дип аңларга кирәк. «Казанны алганнан соң 5 ел сугыш вакытында, 700 меңнән артык татар халкын үтереп, күп сугышчыларын әсирлеккә алдык. Казан ханлыгы җирендә бик аз халык калды. Алары да хәлсез, көчсез, гади кешеләр, шулай ук җир эшкәртүче икмәк үстерүчеләр генә калдырылды». Рус елъязмаларында китерелгән саннар арттырылган дип алганда да афәтнең ни дәрәҗәдә булганын чамаларга мөмкин.

Буйсынмаган, исән калган татар халкы көнчыгышка һәм төньяк җирләргә чигенә. Казан белән Нугай Урдасы татарлары бергә аралашып яши. Бу тыгыз бәйләнешләр нәтиҗәсендә татар халкы бербөтен булып берләшә. Аларны инде аерып санау да дөрес булмас.

Татар дөньясы яңа шартларга җайлаша, төрле катламнар арасында тарихи сирәк була торган рухи берләшү барлыкка килә. Гади тормышлы татар халкы, үзенең татар элитасы һәм дин әһелләре белән бердәм булып, бер-берсенә ярдәм кулы сузып яшәргә өйрәнә.

Шуның бер мисалы: татар халкы дәүләтчелеген югалтып та, бер вакытта да крепостной, яки башка шәхес ирегә булмаган тормышта яшәмәгән.



● Нугай Урдасы картасы.

КАМА АРЪЯГЫ ТӨБӘГЕ ТАТАРЛАРЫ ТАРИХЫ

Рус патшасы Алексей Михайлович 1651 елда чыгарган закон Кама аръягы төбәгендә халыклар тормышын тамырдан үзгәртә. Аның нигезендә «Закамская Засечная линия» төзү башлана. Аны төбәккә күчерелгән руслар, поляклар, мордва, чуаш, чирмеш халыклары, шулай ук Белопахотный солдатлар сословиесе төзи.

Христиан диненә күчмәгән татар морзалары һәм башка татарларның җирләре патша Федор Алексеевичның 1681 елдагы законы нигезендә тартып алына, үзләре исә ясаклы татарлар һәм йомышлы татар сословиеләренә кертелә. XIX гасыр уртасына мишәр һәм типтәр сословиесе кешеләре башкорт сословиесенә күчерелә, алар «яңа башкортлар» дип атала башлый.

Идел елгасы бассейны белән Урал таулары арасында яшәгән татарларга килгәндә дә башкорт темасыннан китеп булмый. Бу турыда, берничә тарихи китапка анализ ясалса, хәзерге чор өчен бик катлаулы булган сорауларга анык җавап алырга мөмкин булыр иде. Шуларның берсе – «Памятная книжка Уфимской губернии. Ч. 1, 1873 г.»:

«Башкорт сүзе ике төрле кулланыла. Аның беренчесенә административ сословие буларак башкорт нәселләре генә түгел, ә шулай ук чирмеш, вотяклар; типтәрләр һәм мишәр сословиеләре кертелә. Соңгы 3 се берләштерелеп, яңа башкортлар дип атала. Мишәрләр дә башкортлар арасында вотчинникларга әверелеп, этнографик яктан тулысы белән охшаш тормышта яши башлады. Аларны аеруның кирәге юк. Әгәр раса һәм кан принцибы буенча бүлсәк, башкортлар үзләре генетик яктан әһәмиятләрен югалтур, үзләре генә тарихи аерым элемент булудан туктар иде. Типтәрләргә килгәндә, 1865 елга алар да башкорт сословиесенә кертелде.

Рус тарихчылары күзлегеннән дә кемнәр хисабына башкорт сословиесе саны артуы яхшы аңлатылган. Рус дәүләте идеологларына башкорт халкы санын арттыру бик зарур булганы аңлашыла. Йөзләрчә ел буена русларның иң көчле тарихи көндәше – татарлар. Татар җирләренә юридик яктан хуҗа булу өчен, татар халкын ваклап, төрле сословиедә булган төркемнәргә, яки турыдан башка халыклар эченә язу, рус дәүләте идеологлары ягыннан караганда иң дөрес һәм уйланылган алым.

Табигый башкортларның нибары 40 мең булган халкы, тиз арада, миллионнар белән саналган татар халыклары арасында «кушылып» юкка чыгар иде. Шуның белән рус патшалары уйлап чыгарган «Башкорт дигән аерым тарихи элемент» төзү тормышка ашмыйча, рус дәүләте тормышында «татар» термины төп билгеләүче булып сакланып калыр иде.

1739 елда табигый башкорт халкының гаиләләр саны 7200, җан саны 200000 гә якын кеше булган. 1865 елда Уфа губернасы төзелгәннән соң басылган статистика китапларында 617 мең башкорт дип язылса да, аларның 330 меңе мишәр һәм типтәрләрдән булганы билгеле. Калган 287 меңе башкорт дип язылган, ләкин алары да табигый башкортларның санын күрсәтми. 1735 елда Кириллов (Идарә итүче Сенатның обер-секретаре) указы нигезендә, башкорт авылларында көнкүрештәге мәсьәләләрне дөрес хәл итүне, шулай ук, вак җинаятьчеләргә хөкем карарын чыгаруны башкорт казыйларына йөкли. Уңай яклары булуы нәтиҗәсендә күп авыллар үзләрен башкорт итеп яздырта башлый. Хәтта христиан булган халыклар да авыллары белән башкорт булып языла. «Список населенных мест Российской империи. Уфимская губерния. 1887 г.») Башкортлар бервакытта да бәйсез булмаган. Монгол ханнары һәм кенәзләре хакимендә яшәгәннәр. Ул монголларның берләштерелгән исеме – нугайлар дип атала. Аларның тәэсиреннән динен генә түгел, венгр (мадьяр) телен ташлап, татарчага алыштырганнар.

Бу рус тарихчыларының, табигый башкортларга биргән сыйфатламасы.

Башкорт сословиесенә язылган халыклар турында тагын бер тарихи китап: «Историческая записка о местности прежней Уфимской провинции, где был центр древней Башкирии. 1867 г.». Бу китап буенча башкорт булып кемнәр язылуы җентекләп аңлатыла. Иван IV 1557 елда, Урал төбәгендәге Оса даругасындагы Гайнә волосте табигый башкортларның нәселләренә «вотчинник» хокукларын бирә һәм үзенең грамотасы белән беркетә. Бу җирләр Нугай Урдасы татарларының борынгы нәсел җирләре дә була. Табигый башкортлар яңа җир хуҗалары – «вотчинник» итеп билгеләнә. Элекке җир хуҗаларының нәсел-ыруг җирләре тартып алынып, алары «припущенник» итеп, «вотчинник башкортларга» оброк түләүче итеп калдырыла.

«Бу җирләрнең элекке хуҗаларыннан булган күп татарлар, Сенатка раслатмыйча гына, Алтын Урда һәм Нугай Урдасы чорларыннан калган «борынгы исемлекләрен» урындагы чиновникларга күрсәтеп, башкортларга бирелгән җирләрне «урлап», үзләрен башкорт итеп яздырып, «вотчинник-башкорт» булып китә. Урал төбәгенә башкорт вотчинниклары рөхсәте белән дә, рөхсәтсез дә бик күп халыклар күченеп утыра. Бик күп фин кабиләләре – чирмеш, вотяк һәм мордвалар; әлбәттә, типтәр һәм мишәр сословиесе татарлары; качып килгән рус халкы килеп төпләнә». Аннары: «Урындагы җирлек җитәкчеләре исәпкә алуларны үткәрмәгән. Бу хәлләр турында, ул чорда, югары җитәкчеләргә билгеле дә булмаган...» Пугачев восстаниесен бастырганнан соң, 1775 елга, Россиядә борынгы табигый башкорт кабиләсеннән булган чын җир хуҗалары калмады».

1801 елда 100 мең атлы азиатлар, төрле күченүчеләр, күбесе хөкүмәткә билгеле түгел, алар үзләрен борынгы башкорт нәселләре итеп күрсәтеп, җирләр таләп итеп алган. Монда шулай ук, татарлар Алтын Урданың борынгы ханнары исемнәре бирелгән авыллары төзеп, күченеп утырды», – дип язылган. Бу аңлатма дөрес булса, фин-угор халыклары вәкиле саналган табигый башкортлар калмаган!

Төрки халыкларыннан гына торган, башкорт булып язылган күченеп килгән 100 меңле атлы «азиатлы», җирле нугай, Казан, мишәр, типтәр татарларының варислары - хәзерге башкортлар булып чыга. Шулай итеп, без барыбыз да татарлар, яки төрки туганнар булабыз.

Вотчинник булудан туктаган һәм башкорт сословиесенә кергән татар, чирмеш, вотяк, мордва һ.б. халыклар үз милләтләренә кайтуны кулайрак күрә. Башкорт сословиесе саны кими һәм аның урынына башкорт милләте дигән сүз кулланыла башлый.

Кызганыч ки, хәзерге чорда кайбер идеологлар «башкорт сословиесенең саны» белән «башкорт милләте санын» тигез итеп күрсәтергә тели. Әлбәттә, бу эшләр күп милләтләрнең, бигрәк тә татар милләтенең ризасызлыгына китерә.

Россия һәм башка дәүләтләрнең архивларында, тарихи китапларда татар һәм башкорт турында гаять күп мәгълүмат табарга мөмкин. Шуларны җентекләп өйрәнү, тарихи дөреслекне ачарга ярдәм итәр иде.

Нәкыйп ГАФИЯТОВ,
төбәк тарихын өйрәнүче.
Минзәлә районы.

Салават РӘХМӘТУЛЛА

Боргаланып аккан сулар сыман, Бу дөньядан узып барышым...

(Танылган шагыйрь Салават Рәхмәтулланың тууына 80 ел)

* * *

Мин дөньяга әйтеп килмәдем бит,
Кемнәр белгән минем туасын?!
Үзем тумас элек барысын да
Кем әзерләп миңа куйган соң?

Туасымны әллә кайдан белеп,
Матур исем сайлап куйганнар.
Көтеп торган мине йомшак куллар,
Тәмле ашлар, җылы юрганнар.

Газиз әнкәм, көн-төн йокламыйча,
Айлар буе көткән, күп көткән...
Язлар, җәйләр, көзләр, кышлар көткән,
Кошлар юлы көткән, күк көткән.

Серләренә төренеп, юллар көткән,
Кавышулар көткән, сагынсам.
(Юлга сала торган законнар бар,
Юлларымнан читкә тайпылсам...)

Сокланырга зәңгәр кичләре бар,
Таңнары бар көтеп алырга.
Үзәкләргә үтәр җилләре бар,
Давылы бар каршы барырга...

Җаныма ни кирәк – барсы да бар
Шушы якты дөнья йөзендә.
Күгемнең дә куе зәңгәрлеге
Зәңгәрләнә зәңгәр күземдә.

Галәмемә йолдызларын тезеп,
Ай элгәннәр, кояш элгәннәр...
Мин дөньяга әйтеп килмәдем бит,
Туасымны алдан белгәннәр!..

МИНЕМ ТАВЫМ

Һәр шагыйрьнең үз тавыдыр...
Роберт Миңнуллин

«Уралым!» дип, дала малайлары
Кунаклаган Уфа тавына...
Очлытавым!
Кала ташларына бәрелә-сугыла,
Шигырьләрем сине сагына.

Җырлы-гармунлы туган як,
Шигырьле туган авыл:
Минем дә тавым бар монда –
Очлытау дигән тау ул!

Түбәсенә менеп бассам,
Җырлар ургылды җаннан.
Ләкин... Уфа да, Казан да
Күренми торды аннан.

Эстәрле күренде – киттем,
Балта салып биштәргә:
Төзүчеләр кирәк икән
«Бөек төзелешләр»гә!

Төзүчеләр дә җырларга
Лаек икән, чыннан да!
...Уфа да, Казан да никтер
Күренмәде моннан да...

Вузда белдем (бу кадәр күп
Белер идем кайларда?!):
Казан Иделләрдә икән,
Уфа – Урал тауларда!..

...Балта тота белгән куллар
Каләм дә тотты әле.
(Каләм тота белмәгәннәр
Кулга да сукты әле...)

Уфага да, Казанга да
Шигырьләр китә торды:
Минем шигырьләрне алар
Китаплар итеп бастырды,
Җырлар да итә торды!..

Шагыйрь таулы була! Өмет
Юк таусыз калганнардан...

...Очлытавымның түбәсе
Күккә тигәндер – күренгән
Уфалар, Казаннардан!..

Кайтып, Очлытауга менсәм –
Җырлар ургыла җаннан:
Мәскәүләр, Парижлар хәзер
Күренә миңа аннан!..

БУРАННАР

Кыш – бураннар чагы...
Бүген тагы
Дворниклар таңнан торганнар:
Кала урамнарын көртләр баскан,
Төне буе шашкан бураннар...

Каладагы буран буранмыни?
Авылдагы буран бурандыр...
...Мин яшәгән йортка салган карны
Хәзер
Кемнәр көри торгандыр...

Шунда тудым!
Тордым!
Оя кордым!
Чәчтем-урдым!
Ауса – тердем!..
Бишмәтемне читәннәргә элеп,
Таңнар саен карлар көрәдем!..

...Ничә еллар мин калада хәзер
(Кабул булды хатын теләгән...):
Җәй үтеп,
Бер чалгы селтәгән юк,
Кыш үтеп,
Юк карлар көрәгән...

...Кала урамнарын көртләр баскан,
Дворниклар таңнан торганнар...
Калаларда буран буранмыни?
Авылда ул
Иң чын бураннар!..

Авылым да
Таңнан уянгандыр,
Авылда бит һаман йөрәгем...
...Импорт дублёнкамны салып ташлап,
Тротуардан карлар көрәдем...

АГА СУЛАР

Узган гомер кире кайтмый,
Сулар үргә акса да...
Халык җыры

Башкаемны учларыма кысып,
Бата-бата тирән уйларга,
Күзләремне тутырып карап торам
Боргаланып аккан суларга...

Аккан сулар, гомер юлы сыман
Башлана да җырлап-чылтырап,
Күкрәк көче белән җир актара,
Беркемнән дә тормый юл сорап.

Чирәм яра, таулар булса – тишә,
Ташлар булса – кисә: юл сала! –
Елга булып, диңгезгә юл ала,
Чыккан чакта чишмә булса да.

Ярларына сыймый шаулап ага,
Диңгез шиңәр сыман – туктаса.
(Үзе диңгез булыр иде, ярлар
Чытырдатып кысып тотмаса...)

Аккан сулар – узган гомер сыман...
Бата-бата тирән уйларга,
Күзләремне тутырып карап калдым
Боргаланып аккан суларга...

Эх, боралмам гомерем агышларын,
Боралсам да сулар агышын!..
...Боргаланып аккан сулар сыман,
Бу дөньядан узып барышым...

ГАРМУН

Рамил Шәриповка

Туган йортка кайтсам, күршем керә,
Гармун белән керә... Уйлыйсың:
«Тагын елар инде...»
– Уйна, җаным!..
– Юк, син, брат, моңлы уйныйсың...
Һәм гармунын тезләремә куя:
Каешларын салам иңнәргә.
...Сагындырган туган-үскән җирләр,
Сагышларны сөйлим кемнәргә?..

Аңламаслар, тыңламаслар барыбер.
Телләренә басам гармунның,
Күрекләре өзелердәй тартам
(Ни икәнен беләм зар-моңның...)

Ә күршемме?.. Башын читкә борып,
Керфекләрен сөрткәч эндәшә:
– Бигрәк моңлы уйнатасың, брат,
Елатасың, брат, мең яшә!..

«Мең»нәр яшәү тәтемәс тә... ләкин
Вакыт җитми китмик, и җаным!
Ә уйнауга килсәк...
Гармуның шәп:
Күрекләре тулы моң аның...

* * *

Сине үзем уйлап чыгардым мин
Һәм
Төшемдә күрдем соңыннан,
Зәңгәр күлдә йөзгән аккош сыман,
Йөзеп килдең зәңгәр болыннан.

Күзләреңнән моң сирпелә иде,
Нур бөркелә иде йөзеңнән.
Кулларыңда зәңгәр чәчкә иде,
Толымнарың иде тезеңнән.

Ал томаннар күтәрелеп калды
Без елмаеп узган болыннан...
Өннәремдә зәңгәр болыннардан
Табалмадым сине соңыннан.

Табалмадым, ләкин табармын мин,
Танырмын мин сине төсеңнән:
Күзләреңнән моң сирпелеп тора,
Нур бөркелеп тора йөзеңнән.
Кулларыңда синең зәңгәр чәчкә,
Толымнарың синең тезеңнән...

ОЧРАШУЛАР

Таулар белән таулар очрашмый да.
Кеше белән кеше очраша:
– Хәлләр ничек?..
«Ничек хәлләр?» – диеп,
Әллә кемнәр туктап сораша.

Танышлар да кебек...
Түгелләр дә.
Кайда? Кайчан күрдем үзләрен?..
Үз хәлләрен сөйлиләр дә... миннән
Көтә алар җавап сүзләрен.

Һәм... яңадан сөйли башлый алар:
– Тулай торак!..
– Кызыл почмаклар!.. –
Шигырь кичәләре уздыргабыз,
Хәтердән дә чыккан ул чаклар.

...Күпме кала,
Күпме авылларда
Күпме шигырь сөйләп кителгән!
Шагыйрьләргә охшап йөрелгән бит:
Автографлар бүләк ителгән...

Шагыйрь булып булмый,
Туган халкың
Шагыйрь итеп сине белмәсә.
Халык тудырмаса, шагыйрь тумый,
Шагыйрь үлми, халык үлмәсә...

...Хәлләремне, җанкисәккәйләрем,
Сез аңлагыз минем җыр аша:
Узып барабыз без
Кылдан нечкә,
Кылычлардан үткен чор аша!..

КОЯШ АРТЫННАН ЙӨГЕРӘМ

Көннеке көндә бетмәде:
Өелеп калды эшләр.
Ашаган ашлар аш түгел,
Төш булмас күрер төшләр.

Сәгатьләрнең кайсылары
Кем белән зая узган?
Вакыт, ашыкма беразга,
Вакытың булса кызган!

Минутларның ничаклысын
Ниләргә сарыф иттем? –
Баеп барган кояш сыман
Кызара ике битем.

Кояш артыннан йөгерәм,
Җаннарым тала-тала:
Көннеке көндә бетмәсә,
Елныкы... елга... кала...

ҖЫРЛАРЫ ҺАМАН КҮҢЕЛДӘ

Рифкать Гомәровның тууына 80 ел

Атаклы музыкантның вафатына чирек гасыр үтеп китте инде, ә җыр һәм милли моңыбызны сөючеләр һаман аны сагына. Без Рифкать Гомәров дисәк - «Саз» халык вокаль ансамбле, «Саз» дисәк, Рифкать Гомәров күз алдына килеп баса. 1968 елда оешкан бу коллектив Европаның бик күп илләрендә: Румыния, Чехословакия, Болгария, Венгрия, Германиядә гастрольләрдә булды. 1970 еллар «Саз»ның чәчәк аткан чагы иде. Ул әле һаман да чыңлый, халыкка хезмәт итә.

Рифкать Әхәт улы Гомәров 1942 ел башында Татарстанның Чирмешән районы Кара Чишмә авылында туа. Ятимлек аны гомере буе эзәрлекли. Башта этисе фронтта һәлак була, аннары әнисе дөнья куя. Әтисе фронтка киткәндә, ул карында гына кала, шулай да Әхәт абзый нәзер әйтергә өлгерә: «Малай туачак, Рифкать исеме кушарсыз», - ди. Кечкенә малай әнисе тәрбиясендә үсә. Әмма озакламый җиде яшьлек сабый бөтенләй ятим кала. Әнисенең әнисе аны үз канаты астына сыендыра.

Сагышлы бала яшьли җыр-моңга гашыйк була, күршеләреннән тальян гармун табып, үзлегеннән уйнарга өйрәнә. Ул вакытта татар сәхнәсенең йолдызларына әверелгән мәшһүр баянчыларыбыз Мөхтәр Әхмәдиев һәм Рокыя Ибраһимованың уйнауларын пластинкадан тыңлый. Бу ике останың уйнавы яшь Рифкатьтә сәнгатькә, җыр-моңга мәхәббәт уята.

1956 елда Кара Чишмә авылына ул чорның зур артистларыннан берсе, олы талант иясе Әзәл Яһүдин концерт белән килә. Үзе җырлый, сөйли һәм, әлбәттә, кечкенә аккордеонда сыздырып җибәрә. Рифкать әлеге артистны кызыксынып, онытылып, йотлыгып тыңлый...

Ат җигеп колхоз эшендә эшләүче Рифкатькә икенче көнне Әзәл ага Яһүдинне күрше авылга - Бәркәтәгә илтеп куярга туры килә. Клуб янында җыелган халык Әзәл Яһүдингә: «Рифкатьне укытырга кирәк, ярдәм итсәгез иде», – дип мөрәҗәгать итә.

Калганын алар юлда барганда сөйләшеп бетерә. Шушы елда авыл халкы, акча җыеп, Рифкатьне Казанга укырга озата.

Керү имтиханнарын уңышлы тапшырып, Рифкать Гомәров 1959 елда Казан музыка училищесында укый башлый. Баяны булмау сәбәпле, училище директоры Ильяс Әүхәдиев Рифкатьне Мөбарәк Батталов укыткан гобой классына тәкъдим итә. Ул анда озак укымый. Һөнәр училищесына укырга китә, чөнки бирердә өч тапкыр бушлай ашаталар һәм киендерәләр. Ә музыка училищесында стипендия дә аз була, гобой да ошап бетми, һөнәр училищесын тәмамлап, слесарь-җыючы дигән белгечлек алып чыга егет. Рифкать училищеда укыган елларда ук «Спартак» аяк киемнәре берләшмәсенең М.Горький исемендәге клубына йөри башлый, үзешчән сәнгатьтә актив катнаша. Баян буенча Виктор Яковлевтан дәресләр ала. Уку түләүле була. Ләкин Рифкатьнең ятим икәнен белгәч, укытучы аннан акча алуны туктата. Әлеге егетнең баянда уйнавына тиздән профессиональ җырчылар да игътибар итә башлый.

Бервакыт Рифкатьнең уйнавын Зифа апа Басыйрова тыңлап тора. Үз янына дәшеп сөйләшә дә тиздән аны Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенә алып килә. Ул вакыттагы директор М.Ф.Боголюбов Рифкатьне, һөнәрчеләр училищесын тәмамлагач, филармониягә эшкә килергә чакырып кала. 1959 елда Р.Гомәров филармониядә эшли башлый, аны Әлфия Авзалова бригадасына билгелиләр. Соңрак яшьләр бригадасы оештырыла: җырчылар Әлфия Авзалова, Илһам Шакиров, нәфис сүз остасы Рафаэль Галиев, баянчы Рифкать Гомәров... Элеккеге Советлар Союзы буйлап гастрольләр башлана. Армия сафларында хезмәт итеп кайткач, Рифкать яңадан филармониядә эшләвен дәвам итә.

Бервакыт Уфа шәһәрендә гастрольдән соң Р.Гомәровка Әлфәрит Солтанов мөрәҗәгать итә (ул заманнарда Ә.Солтанов Башкортстанның иң оста баянчыларыннан берсе була. Аның уйнавын Татарстан радиосы да еш яңгырата иде): «Энем, моңлы да уйныйсың, бармакларың да йөгерә, ләкин нишләп басларны унисон уйныйсың?» — ди. Музыкаль белеме булмаган Р.Гомәров сул яктагы аккордларга басмый гына уйный. Сәбәбе - мажорны минордан аермау. Алга таба музыкаль грамотасыз эшләү мөмкин булмый, һәм Рифкать үзенә сүз бирә: укырга. Бары тик уку гына аны коткара алачак. Ул 1967 елда Казан музыка училищесына кабат укырга керә. Бу юлы инде: «Баян классына егерме биш яшьлек күсәк укырга килгән», — дип, Ломоносовтан көлгән кебек, Гомәровтан көләләр. Геннадий Шаронов классында белем алып, музыка училищесын ул 1971 елда тәмамлый. Р.Гомәров 1968 елда «Тасма» берләшмәсе клубында «Саз» кызлар вокаль ансамбле оештыра. Ансамбльне күп тавышка җырлату өчен училищеда баян классында алган белем генә җитми. Шуңа күрә Рифкать 1971 елда Казан дәүләт мәдәният институтының хор дирижерлыгы бүлегенә укырга керә.

Институтны тәмамлагач, клубта ансамбль белән эшләвен дәвам итә, бер үк вакытта шул клубта директор вазифасын да башкара. Ансамбльгә кызларны мәктәпләрдән, техник училищелардан җыя. Татарстан һәм Россиянең халык артисткасы, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры солисткасы Венера Ганиева, сүз остасы, пародияче Алмаз Хәмзин кебек талант ияләре сәхнәдәге беренче адымнарын Р.Гомәровның «Саз» ансамблендә башлый. Ул гына да түгел, унбишләп вокаль ансамбльнең булачак җитәкчеләре дә Гомәров мәктәбен уза.

Р.Гомәров берничә чит илдә булып кайта. 1960 елда ул Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе артистлары белән Вьетнамда, Кытайда һәм Кореяда гастрольләрдә була. Концертлар зур-зур стадионнарда уздырыла, халык бик яратып тыңлый, чөнки аларның музыкасы да пентатоникага нигезләнгән. (Гади тел белән әйтсәк, аларның музыкасы да «татарча».) Татарстан артистларын ул вакытта җылы каршылыйлар: Пекиннан Ханойга очарга Хо Ши Мин хәтта үзенең шәхси самолетын бирә. Вьетнам халкы татар артистларын чәчәкләргә, алкышларга күмә...

«Саз» ансамбле җырлаган барлык җырларны Р.Гомәров үзе эшкәрткән. Ә инде аның үзе язган җырлары телдән телгә күчеп яши бирә.

Кирам САТИЕВ.

Театр бинасы проекты өчен дөньякүләм конкурс игълан ителгән иде. Татарстан Республикасы мәдәният министры Ирада Әюпова соңыннан матбугат конференциясендә билгеләп үткәнчә: «Безнең конкурс аша бөтен дөнья безнең мәдәнияткә кушылды. Бу конкурс тарихыбызны, милләтебезне, мирасыбызны популярлаштыру өчен бик мөһим».

Дөнья күләмендә танылган архитектура бюролары үз проектларын тәкъдим итте. Билгеле шәхесләрдән һәм татар интеллигенциясе вәкилләреннән торган жюри алар арасыннан өчесен сайлады. Очколар кушылып, җиңүче сайланды. Проектларны тәкъсәбәпле, тамаша залларына йөрмәү яклы булып, андый сәфәрләрне туктаткан идем», – дигәне дә булды. Шуңа күрә талар проектны яклаганмы, әллә Бикчәнтәев җитәкләгән театрнымы — монысы һәрберсенең үз җаваплылыгында.

Архитектор, «Кол Шәриф»

КАМАЛ ТЕАТРЫ БИНАСЫ:
фикерләр төрле

дим итү утырышы онлайн узды. Дөрес, фикер алышуларның иң кайнарын күрмәдек, хәтта жюри таралганда да кем җиңгәнен белмәгән – монысын матбугат конференциясендә Фәрит Бикчәнтәев ассызыклады. Җиңүче проектны игълан итүгә багышланган матбугат конференциясендә ул әлеге фикер алышуларны «Театральное представление»не хәтерләтте, диде. «Сила искусства», дип өстәде И.Әюпова.

И.Әюпова үзе, Казан мэры Илсур Метшин, шәһәрнең баш архитекторы Илсөя Төхфәтуллина башка проектны – бик аз гына аерма белән икенче урынга калган «Асиф Хан»ны – яклаган. Илсур Метшин «япон проектын» Бикчәнтәев яклавын әйтте: «Кичә сезнең фикер хәлиткеч иде. Сез театр бинасына заказ бирүче һәм үзегезгә ошаган проектны ассызыкладыгыз».

Димәк, без шундый нәтиҗә ясый алабыз – Ф.Бикчәнтәев зур көчләргә каршы көрәшкә чыккан. Аның артында – театр труппасы һәм жюри әгъзалары булараk сайланган татар язылылары вәкилләре тора. Ул зыялылар арасында бөтенесе театраль дия алмыйбыз. Арадан берсенең: «Пандемия булу мәчете проекты авторы Айвар Саттаров: «Минемчә, бу проект татар мәдәниятенә, татар эстетикасына бер яктан да килешми. Бу безнең өчен чит эстетика. Андый биналар белән хәзер бөтен дөнья тулган. Аның агрессив формалары безгә килешми, анда татар җаны да, хисе дә юк. Барлык проектларны карап чыктым, берсендә дә татар рухы юк. Бөтенләй юк! Инглиз архитекторының икенче урын алган проекты азмы-күпме килешә иде. Анда да татарлык юк, ләкин аны эшләп бетереп була иде.

Мин конкурста катнашмакчы идем – кертмәделәр, чыгарып ташладылар. Чит архитекторларның эшләре элек тә булды, мәсәлән, Милли китапханәне эшләделәр. Алар Казанны белми, бер-ике килеп кенә шәһәрне аңлап булмый. Казан рухын алар сизми. Алар дөнья буйлап космополитик эстетика тарата. Без инде дөнья югарылыгында дип шатланабыз, алдыңгы дибез, «продвинутый» дибез, тегесе, бусы…

Пирамида төзелгәнне хәтерлим әле, «Мировой уровень» дип кул чаптылар. Минемчә, ул булмаса да хуш, бигрәк чит әйбер булып тора. Төзелеп беткәч түгел, төзегәндә үк проектның чит әйбер икәне күренәчәк. Ә безнең татар театры бинасы кебек объектлар мәңгелеккә барырга тиеш.

Заманында беренче татар архитекторы Исмәгыйль Гайнетдинов Опера театры бинасы проектын ясады. Ул утызынчы елларда да матур иде, хәзер дә матур. Ә бу проектны бүгенге буыннар «йотса», киләчәк буын ничек карар? Фикерем шул – бу проект Казанга килешми».

Халык язучысы Марсель Галиев үз фикерен аккаунтына язган: «Татарны башкалабыз үзәгеннән куу бара. Яңа театр бинасының сурәтен күргәч, бу фикерем тагын да ныгыды. Театр бинасы классик архитектура чалымында төзелергә тиеш. Күркәмлеге гасырларга барырлык бина булырга тиеш! Ә бу… Җир тетрәүдән соң өелеп калган бетон кисәкләреннән торган чүп өеменә охшаган. Үзәктән читкә тибәрелгән театрга иң актив буын — урта һәм өлкән буын тамашачысы йөрмәячәк. Театр үз теләге белән тамашачысыз калырга уйлый, күрәсең».

Драматург Мансур Гыйләҗев: «Мин театрның кучүенә каршы идем, проектны күргәч, бик ошады. Ул гаҗәеп! Безнең шәһәрне баетачак — аның архитектурасында зур яңалык булачак! Мин фикеремне үзгәрттем — хәзер инде урынынан да канәгать! Бу проектны элеккеге урынына салсалар, тагын да яхшырак булыр иде, ләкин тегендә дә әйбәт булачак. Бу проект — космос! Андый театр Россиядә дә юк! Бу гаҗәеп күренеш булачак! Ул миңа космостан килгән могҗизаи кораб булыр кебек тоелды.

Ләкин ул проектның бер ялгышлыгы бар: ул безнең климатка туры килми. Япониядә башка климат. Шуңа күрә эксплуатация вакытында читенрәк булачак һәм бик кыйммәткә төшәчәк. Чөнки бездә кар ява, быелгы кебек кыш булса, аны кар басачак. Ләкин матур, халык кына йөрсен! Ә халык бинаны күрергә йөриячәк! Һәрхәлдә, беренче вакытта халык булачак анда. Аннары инде театрның үзеннән тора…»

Әдәбият белгече Миләүшә Хәбетдинова: «Бу татар халкына бүләк ителгән «коры ботак». Республика татар халкына шундый «бүләк» ясарга җыена. Бина агрессив-җимергеч кыяфәтле. Бизәлеше ерактан татарныкы кебек күренсә дә, төсләр фактурасы, бизәкләр композициясе традиция бозылуын күрсәтә. Бина күренеше югарыдагыларга якынайтылган «татар интеллигенциясе» тирәлегендәге җимерeклекне символлаштыра. «Татар интеллигенциясе» буларак комиссиягә кертелгән кешеләр Казан үзәгеннән татарлыкның кысып чыгарылуы өчен, милли мәдәнияттә формализм өчен шәхси җаваплы. Иң куркынычы – милли характерның җимерелә баруы. Нәтиҗәләре тиздән күз алдында булачак.

Милли мәдәният татарларның үз куллары белән читкә чыгарылса да, мин әле халыкка ышанам. Лев Толстой безгә үлмәс татарник образын бүләк итеп калдырды. Милләткә бу кадәр басым эзсез үтмәс – саклану тенденциясе эшләр.

Мин урын саны мәсьәләсендә техзадание вакытында ук тавыш күтәргән идем. Камал театры бинасы – татар дөньясы өчен бердәнбер академик бина. Мәскәү театрларындагы урыннар саны белән чагыштырмасыннар. Русның үзтәңгәллеген ныгыта торган биналары күп, бөтен дөнья татарларын Казан үзәгенә җыя ала торган башка андый бинабыз юк. Татарларны җыйган чаралар урын саныннан чыгып билгеләнә, урын аз икән, кунаклар чакыру өчен квота да үзгәрә. Димәк, татар үзен үзе кыса булып чыга».

М.Хәбетдинова фикерен дәвам итеп, Камал театрының зур залы 600 урынлы булачагы – ни кызганыч, театрның техзаданиесе. Театр тамашачылар санын кыскартырга карар иткән. Театр үз теләге белән 242 татарын кысрыклап чыгарды – элеккеге залдагы 842 урынына 600 урын гына булачак. Әлбәттә, бу аншлаглар ясауның һәм план үтәүнең җиңел юлы. Әйе, театр залы зур булмый диючеләр дә хаклыдыр. Әмма «Поэт в России – больше, чем поэт», дигәндәй, татарның Камал театры – театр гына түгел, ул татарның татарлыгын ныгыту, рухын баету, бер-берсен тою урыны. Татарның мәйданы да театр иде… Камал театры мәйдан булырга теләми, ул бары тик театр гына булырга телиме?

Миллион ярым башкортның академтеатрында 500 урын булып, 7 миллион татарның академтеатрында 600 урын булачакмы?

Миллионнан артык халкы булган Казанның беренче санлы театрына 600 тамашачы гына сыячакмы?

Рузилә МӨХӘММӘТОВА.

intertat.tatar

Хәтер җепләре

15 февральдә Хужа Хәсән авылының кулына корал алып, 41 нче пулемет полкы составында Ватанны саклаган бердәнбер хатын-кызы Ольга Власовна Данилованың (Кузнецова) дөньяга килүенә 100 ел тулды.

РФ Оборона министрлыгы архивы белешмәсе нигезендә, әлеге полк 1943 елда Курск шәһәреннән дошманны куа, Украина, Польшаны азат итүдә катнаша һәм 1945 елның 28 мартында Германия территориясенә үтеп керә. Ольга Власовна Берлинны штурмлап алуда да актив катнаша. Ул пулеметчылар бүлеге командиры була. Берлинны алуда актив катнашкан өчен, сугышчан дәүләт бүләге белән дә бүләкләнә. Сугыш Ольга Власовнаның сәламәтлеген бик нык какшата. Ул 1961 елда 39 яшен дә тутыра алмыйча вафат була. Аның 5 баласы әнкәсез ятим кала.

Кызганыч, моңарчы О. Данилованың каберендә Бөек Ватан сугышында катнашучы буларак истәлек билгесе дә юк иде. Хужа Хәсән мәктәбенең элеккеге укытучысы, Бөек Ватан сугышында батырларча көрәшкән күп балалы ана истәлеген мәңгеләштерү максатыннан 2017 елның 4 июнендә РФ Дәүләт Думасы депутаты Илдар Гыйльметдинов ярдәме белән О.Данилова-Кузнецова каберенә, ниһаять һәйкәл урнаштырылды, ә бөтен чыгымнарын Яшел Үзән район Башкарма комитеты каплады. Шул ук вакытта Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы, Мәдәният министрлыгы, Татарстанның Сугыш ветераннары советы һәм О.Данилованың язмышына битараф булмаган бик күп гади кешеләр Хужа Хәсән авыл җирлеге башлыгы һәм Кайбыч район хакимиятенә дә мөрәҗәгать иткән иде.

2020 елның июнь аенда Кайбыч районы хакимияте башлыгы А.И.Рәхмәтуллин, авыл җирлеге советы башлыгы С.П. Матвеева белән Хужа Хәсәндә җыелышлар үткәреп, авылыбызның Центральный исемен йөрткән тарихи "зур урам"ын "Ольга Данилова урамы" дип атарга карар кабул иттеләр. Бу вакыйга Ольга Власовнаның нәселе, авыл халкы өчен дөреслек һәм гаделлек бәйрәме булып, җаннарында горурлык хисләре уятты. Хәзер инде О. Данилованың фоторәсеме дә Тау ягы татар керәшеннәре музеенда Туган якның күренекле шәхесләре сафында балкып тора. Ольга Власовнаның балалары, онык-оныкчыклары, якыннары, бертуган энесе, шулай ук авылдашлар исеменнән бик зур рәхмәтебезне Кайбыч районы хакимияте башлыгы А.И.Рәхмәтуллинга, Хужа Хәсән авыл җирлеге башлыгы С.П.Матвеевага һәм РФ Дәүләт Думасы депутаты И.Гыйльметдиновка юллыйбыз. Бу мәсьәләне уңай хәл иткән өчен намуслы, горур халкыбызга Ходайның рәхмәте булышсын иде.

Барысы исеменнән
Вячеслав ДАНИЛОВ.

Рауль МИРХӘЙДӘРОВ

Спрут заманы

(Дәвамы. Башы 5-6 нчы саннарда).

Сабир-бобо, күрәсең, алдан күрә белгән: зур мөселман бәйрәмнәрендә бер генә мәчет тә бу кадәр диндарларны сыйдырып бетерә алмас иде, ә бу мәчет алдындагы Зур мәйданда барысына да урын җитәчәк. Ә инде намазга җыелган халыкны Ленин карап тора икән – зур бәла түгел, заманында аңа да җитмеш елдан артык табынганнар бит, нәтиҗәсе һәркемгә билгеле. Ахыр чиктә, Аллаһы Тәгалә дә һәр кешегә бәхет һәм тигезлек вәгъдә итмәгән. Аннары Ленин биредә бик озак тора да алмас: Россиядә, Украинада, Молдавиядә көн саен диярлек пеләш юлбашчыга куелган һәйкәлләрне җимереп торалар. Мәкальдәгечә: «Ни чәчсәң – шуны урырсың». Үз вакытында юлбашчы фәрманы белән чиркәү-мәчетләрне җимереп бетергәннәр, руханиларны атып үтереп, чиркәү чаңнарыннан унитаз һәм юлбашчыларга һәйкәлләр койганнар, ә хәзер менә аның меңләгән бронза скульптураларын яңадан чаңнар коярга тотарлар – чиркәү-мәчетләр дә хәзер көн саен үсеп чыга тора, ә илдә бакырга кытлык...

Мөселманнарның изге җирләргә хаҗга барып кайтулары безнең өчен әле гадәти булмаган күренеш, шуңа күрә хаҗиларны пәйгамбәрләргә тиңлиләр диярлек. Ә Сабир-бобо ике барып кайтты бит, әле тагын Аксайда үз акчасына мәчет тә салдырмакчы була, шуңа күрә аның абруй-дәрәҗәсе бик нык үсте.

Ил-дәүләттә вакыйгаларның тиз алышынып торуы Сабир-бобоны әле куандыра, әле куркыта да иде. Зур илнең таралып төшүе, республиканың бик күптәннән көтелгән бәйсезлекне алуы, бер караганда, яхшылыклар гына вәгъдә итә. Чит ил прокуратурасының гаепләүләре Үзбәкстанда үз көчен югалтыр, Акмал Арипов үзеннән-үзе иреккә чыгар иде. Ә инде өенә кайткач, Аксай хуҗасы нишләргә кирәген белер, КГБ подвалларында утырганлыктан, сәяси абруе да артыр иде.

Икенче бер нәрсә куркыта... Бәйсез республикада хакимияткә кем килер? Элек һәммәсе дә ачык иде: хөкүмәт, андагы түрәләр Аксайда хәл ителә, хан Акмал хуплавыннан башка беркем дә министр була алмый, алар барысы да танылган, яхшы гаиләдән чыккан, хөрмәткә лаек, җитәкчелек тәҗрибәсе туплаган партия әгъзалары, ниндидер урын биләмәгәннәре турында сөйләшеп тә тормыйлар. Әмма әлегә кадәр тын яткан Үзбәкстанда да халык кайный башлады, кайдандыр яңа әйдәп баручылар пәйда булды -шагыйрьләр һәм әдипләр, галимнәр һәм журналистлар, инженерлар һәм агрономнар... Халык шуларның сайрауларын тыңлый, шуларга ышана, яңа партия һәм төрле агымнарга дәррәү кушыла. Алар республиканы кая алып чыгар, алып чыга алырмы, яки, сүз боткасы пешереп, буш куык кына булып калырлармы? Шәхес хокукларының, милләт-дәүләт мәнфәгатьләре алдында гражданнарның беренчеллеге – монысы нәрсә икән? Совет кешесе бит кечкенәдән үк дәүләт мәнфәгатьләре – иң мөһиме, дигән уй-фикер белән тәрбияләнеп үсә иде. Димәк, барысы да киресенчә булып чыгамы? Ташкенттагы яңа демократлар белән аларның өлкәләрдәге дуслары республиканы кая илтеп кертер? Ә дин, ислам дине нишләп бетәр? Ул дәүләткә йогынты ясый алырмы, яки үзбашка яшәргә хөкем ителерме?

«Юк, бер дингә генә ышанып яшәргә иртә әле, – дип уйлый Сабир-бобо. – Анысы төбәктәге карт-корылар өчен генә, алар дәүләт тормышында төп көч тә түгел, һәммәсен дә элеккечә партия номенклатурасы, урыннардагы җитәкчеләр хәл итә».

Урта Азия республикаларында, бөтен илдәге кебек үк, үзгәртеп кору елларында бернәрсә дә үзгәрмәде диярлек. Килеп туган вәзгыятьтән файдаланып, бер ыругныкылар икенчеләрен куып тарата, биредә бер-берсен батыру һәрчак дәүләт исеменнән башкарыла, халык моны законлылыкның тантана итүе дип уйлый, үзәк тә шул ук фикердә – коммунистлар, җитмеш ел ил белән идарә итеп, Шәрекьне, аның асылын аңлауда бер адым да алга китә алмады. Юк, дәүләт белән идарә итәрлек, аның программасы булган-кешеләрне эзләргә кирәк. Сабир-бобо хәрәкәт итәргә, Ташкент белән элемтәләр урнаштырырга кирәклегенә көннән-көн ышана төшә иде. Шәхсән үзе барып очрашырга тиешле беренче кеше итеп ул Югары суд хезмәткәре Сухроб Әкрәмходжаевның иске дусты һәм күптәнге хезмәттәше Сәлим Хашимовны сайлады.

* * *

Прокурор Камалов алдан чамалаганча, Миршаб Яңа елны куркып каршы алды, әмма гаиләсенә һәм якыннарына сиздермәде, бер дә булмаганча күңел ачты. «Лидо»дан өенә кайтып кергәндә, аларда энесе белән сеңлесе утыра иде инде. Һәр икесе гаиләләре белән килгән икән. Бераздан хатынының туганнары да килеп җитте. Сәлим хезмәтендә бик тиз югарыга үрмәләгәннән соң, зур бәйрәмнәрне гел аларда гына үткәрә башладылар. Урта Азиядә шул рәвешле ырудан иң зур уңыш казанган туганга хөрмәт күрсәтәләр.

Һәркемнең язмышында туган-тумачаның нинди урын тотканын белү өчен Шәрыктә яшәргә кирәк. Ырусыз, туган-тумачасыз кеше, җирле күзлектән караганда – беркем түгел. Биредә кем турында булса да белешергә кирәк булса, иң әүвәл аның кайдан, чыгышы белән кайсы җирләрдән икәнлеген, кемнәр белән туганлашуын сорашалар – теге яки бу кешенең ни өчен хөрмәтле булганлыгы, ниндидер урын биләгәнлеге шунда ук ачыклана.

Хашимов үз ыруы арасыннан беренче булып югары үрләгән, танылган кеше иде. Мөмкинлек туу белән ул тырышып-тырышып күпсанлы туганнарына булыша башлады, күрәсең, үзенең нинди кыенлыклар аша күтәрелгәнен хәтерләгәндер.

Кунакларга булган мөнәсәбәтләрне аңлау өчен дә Шәрыктә яшәү кирәк. Биредә аларны чынлап та ихластан шатланып каршы алалар – кунак килмәгән йорт, мул тормышлы, бай йорт булса да, аңа хөрмәт юк. Бу гореф-гадәтләр күп гасырлык тарихка ия, европалы кешегә, мәсәлән, аңлавы бик кыен: әйтик, ни өчен ярлы-ябагай да автомобиль алырга хыялланмый, ә үз тормышында бер генә мәртәбә булса да бай табын янында өй тулы кунаклар кабул итеп утырырга тели. Бу милли сыйфат рәхимсез өткән кояш астында мамык кырларында бил бөккән дехканның да, Сәлим кебек яхшы тәрбия һәм белем алган кешенең дә канына сеңгән.

Көтмәгәндә-уйламаганда гына «Лидо» ресторанында прокурор Камаловны очраткач, ул гүзәле Нәргизгә Яңа ел бүләге алырга да, бүген үз өендә гадәттәгечә күпсанлы туган-тумача җыелачагын да онытты. Ләкин йорт хуҗасы булу аны үзенә янаган куркынычны вакыт-вакыт онытып торырга мәҗбүр итә иде. Хәтта андый мизгелләрдә дә кунак кунак инде ул. Үзенең туган-тумачаларына алган бүләкләрен дә хәтерли – аларның һәрберсен Миршабның өендә куандырырлык бүләк көтә. Андый яхшылыклар онытылмый, бу юлы ул аеруча юмарт кыланды, чөнки белә – үзе белән ул-бу була калса, туганнары аның хатынын да, балаларын да кайгы-хәсрәттә ялгыз калдырмаячак.

Гадәттә, Мәскәү вакыты белән Яңа елны каршылагач, кунаклар таралыша башлый иде, әмма бу юлы, көлкеле төрле уеннар уйлап чыгарып, йорт хуҗасы аларны таңга кадәр җибәрмәде. Ул бу зур йорт эчендә ялгызы гына калудан курыкты, аның уйлары әле һаман да прокурор Камаловның янаулы сүзләренә әйләнеп кайткалый иде.

Бу кадәр озак мул табын янында һәм чыршы тирәсендә утырырга күнекмәгән кунаклар иртәнге якта аяктан егылыр дәрәҗәдә иде инде, бераз тын алырга дип, тирән күн кәнәфигә бер генә минутка утырган Сәлим шунда залда ук йоклап та китте. Бары тик шуннан соң гына туган-тумачалары, якыннары хуҗабикәгә искиткеч күңелле бәйрәм өчен рәхмәтләр әйтеп, кунакчыл йорттан китә башлады.

Миршаб көн уртасында гына уянды, әйтерсең лә кичәге борчулы көн дә, шау-шулы Яңа ел төне дә булмаган – аның башы саф, гәүдәсе ял иткән иде.

Салкын суда коенып-юынып чыккач, ул, өйдә икәнлегенә бик ышанып бетмәсә дә, Костага шылтыратып алырга булды. Ләкин Джиоев шундук телефон трубкасын күтәрде, Хашимов моны яхшыга юрады. «Лидо»да Яңа елның ничек үтүен, андый-мондый хәлләр булу-булмавын сораштыргач, ул Костаның үзенә кереп чыгуын үтенде. Коста берәр сәгатьтән килергә вәгъдә бирде.

Коста инде Кареннан ресторанда прокурор Камаловның булганлыгын, бөтенесен куркуга салып чыгып киткәнлеген белә иде, ләкин ул Мирша янына бу сәбәп аркасында гына ашыкмады. Кичә, ул инде кәеф-сафа корырга чыгып китәм дигәндә генә, Мюнхеннан Шубарин шылтыратты.

(Дәвамы бар).

Зиннур МАНСУРОВ

ТӘКЪДИР КАЛӘМЕ ТӘКЪЛИТ КЫЛМАС



I

●Сөембикә манарасы ава башласа, каладагы һәйкәл-сыннар кичекмәстән җыелышып, аңарга ныклы иңнәрен куячак.

●Тарих сабагын беренче нәүбәттә хакимнәр даирәсе алырга тиеш.

●Дәүләт идарәсендә һәрчак беренче булып саналган хаким халык арасында үзеннән акыллырак затлар барлыгын белмәс.

●Тормыш кырында алтын урталыкны баррикада белән билгеләп булмый.

●Гомер бәясе торган идеягә сәясәт катнашса, элгәрләр аңлавындагы чын-хак фидаилек очсызлана башлар.

●Әниләре «Улым, өйгә кайт!» дип чакырмаганга күрә, кайбер сәясәтчеләр халык белән уйнаудан туктый алмыйлар.

●Күзгә сыйган җиһанны саф-чиста яшьләрең белән күпме генә юма, кер күтәрми торган ошбу фани дөнья барыбер пакьләнә алмас.

●Мөмкинлекләре чикләнгән үҗәт кешеләр максатларына табан ахыргача баручан.

●Электән килгән тормыш кагыйдәләре кануннарга караганда күбрәкне колачлый.

●Сайлау алды бәйгесендә алдашулар өстен чыгар.

●Сәяси экономия белгече: «Адәм баласының якты киләчәккә бару теләге караңгы мәгарәдә яшәгән чакта ук туа».

●Бераз гына авышып киткән тарихи манаралар да бу дөньяны туры хәлдә кичәргә ярдәм итә.

●Аналарның күз яше тамып торганда дарыны коры килеш саклау кыенлаша.

●Кендек әбиләрен отыры эшсез калдырган авылда заманча хезмәт урыннары булдыру мөмкин түгел.

●Тереклекле кендек каны таммый торса, андый җирне әкренләп килмешәкләр үзләштерер.

●Элгәрләрнең төгәлләнмичә калган игелекле гамәле варислар өчен изге бурычка әверелер.

●Финишка бергәләп килү максат уртаклыгын аңлатмас.

●Белдерү: «Инкыйлаб ясарга теләгән илләргә «Аврора» крейсеры файдалануга бирелә».

●Озын тоннель ахырындагы яктылык ноктасы күпләрнең төшенке күңелен күтәрергә җитә.

●Үзенең кочагындагы бала наянлыгы анага рәхәтлек китерер, үзенең кочагындагы кеше кыланышы табигатькә ачу йоттырыр.

●Изгеләр исәбен чик-чамасыз төстә арттыру гына илнең тормышында сыйфат үзгәрешен барлыкка китермәс.

●Шау-шулы тарих сәгате сукканда йокычыл гавам да уяныр.

●Бәйрәмдә һавага атыласы ук җан кыймавына төшенеп сөенер.

●Мәрхәмәтсез патша заманында татар гаиләләре олы елга тирәсеннән куыла, гуманлы хакимият чорында газиз авыл нигезләре су астында калдырыла.

●Үткәнгә зиратлар аша карасаң, шәхесләр бәһасе ачыграк күренә.

II

●Иркәлектә бозылмаган бала халык сөеклесенә әйләнүчән.

●Җан-рух тирәнлегенә төшеп җырлаган моңчыга масайта торган «йолдыз чире» йокмас.

●Җиде буын зирәклеге вундеркиндта ташып чыгар.

●Мөкатдәс бурычны үтәү өчен рухи көч күбрәк сорала.

●Яшәү мәгънәсен яшьли чынбар тирәнлегендә аңлап алсаң, аннан үзеңә кирәкле уй-фикерләр агылып кына торыр.

●Уй-ният мактануны яратмый.

●Башыгызда уй-фикерләр булмаса, урталык агымына кушылыгыз.

●Билгеле әсәреңне астыртын рәвештә өлешләп урлаучы әдәби каракка караганда ачыктан-ачык «Бу – талау!» дип белдерүче угрылар өстенрәк сыман тоела.

●Һәрбер кеше үзен әйдәп баручы артист вазифасында күрергә хаклы, чөнки адәм баласы шәхси язмышында мотлак баш рольдә уйный.

●Әүвәлге рухи кыйммәтләрне бүгенгегә кайтару кануни яктан урлашу гамәленә тиңләнмәс.

●Өсте аска әйләндерелгән баскыч тарих галимнәренә файда итәр.

●Хәтта иҗатчысы билгесез саналган сәнгать әсәрендә дә чын авторның чалымнарын җитәрлек дәрәҗәдә күзалларга мөмкин.

●Кәгазьгә язылганны сызган чакта каләм башлыча канәгатьлек кичерер.

●Тутый кошның кайбер сүзләрне кешечә әйтергә маташуы халыкларның теленә ярлылану куркынычы янавын искәртеп тора.

●Үз карашыңны белдерү өчен шәхес булып калу шарт.

●Үзсүзле бәндәдән фикердәш эзләмә.

●Сүзен бирмәскә тиешле кайбер кешеләргә урыныннан кузгалмаучы ишәк үҗәтлеге җитми.

●Тома ахмак бәндәдә дә өч тиенлек акыл була.

●Кешенең кем икәнлеге зәвыгыннан да күренә.

●Уң кулың нишләгәнне сулың белсә, синнән яхшы гына гармунчы чыгар.

●Кешенең халык-фигыле сәнгатьтә түгел, гамәл дәфтәрендә тулысынча ачылыр.

●Белемнең тирәнлеген чамаларга мөмкин, тома җаһиллекнең иге-чиге күренмәс.

●Гавам зәвыгына яраклашу музаларны үсендерә алмас.

●Мәктәп дәресләре отыры онытылырга мөмкин, тормыш сабаклары һәрвакыт истә тора.

●Тәкъдир каләме тәкълит кылмас.

●Театр сәхнәсе артында да күп драмалар уйналырга мөмкин.

●Картайган косметолог киңәше: «Матур йөзле килеш үлим дисәң, әчке дөньяң матур булып калсын».

III

●Хатын-кыз затына пәйгамбәр булу насыйп итмәгән, әмма һәркайсы анага изге вазифалар йөкләнгән.

●Ана йөрәге балалары санынча парә-парә телгәләнеп бетсә дә, ул үзенең бәрәкәтле җылысын кадерлеләренә бөтенлек хәлендә бирә.

●Газиз әниләргә җиткереләсе «Яратам» сүзе, гадәттә, ачы бугаз төенендә әйтелмичә кала.

●Сайлап алган гомер мәсләгенең юнәлешен дөресләп бару өчен йөрәк навигаторыннан җиде бабаңның күрсәтмәләрен хөрмәтләп тыңларга өйрән.

●Җир белән күк арасында тирбәлүче элгәрләр бишегә сабыйга ике дөнья турында сабак бирә башлар.

●Үз-үзен гаепли алучы затлар бөтен авырлыкны язмышка сылтамас.

●Язмыш бүләге кыйммәткә төшәр.

●Насыйп язмышыңны сукыр дисәң дә, ул сине ахыргача җитәкләп барыр.

●Мантыйкчылар биргән билгеләмә: «Гомер – гамәлгә ашырылган язмыш».

●Тормышта үз урыныңны табу өчен җиде бабаң белән дә киңәшләш.

●Андый үсенте хайваннарда гына булса да, адәм затлары койрыкны чынлыкта ешрак болгый.

●Сары йортта ихтыярсыз тереклек кылырга мәҗбүр булган инсаннар арасында үзләрен шашынучы дөньяның акыллы өлеше итеп санаучылар да байтак.

●Кара таракан башсыз да тугыз көн яши ала, ә башсыз кемсәләр шактый озын гомер кичерергә мөмкин.

●Чамасыз кыланып елаган чакта күз яшенең сафлыгы югалыр.

●Кошларның кемнедер күктә очып барышлый нәҗесләве кешеләргә пычрак атучы бәндәдә көнләшү тудыра.

●Чебен гөмбәсе – зәһәрле затка: «Синең алдыңда эшләпәмне салам».

●Ата-ана белән балалар арасындагы ярату да бер якның салкынаюына китергән галәмәтләр күзәтелә.

●Хәләл җефетенә кайбер кирәкмәс гамәлләрен сиздерергә теләмәгән ата үз балаларын күрәләтә алдашу юлына кертеп җибәрергә мөмкин.

●Аның яхшы яклары ерак бабаларыннан күчсә, начар сыйфатлары исә үз атасыннан килә.

●Ач күзле нәфесне күрәләтә тыярга теләмәү киләсе буыннарның хәләл өлешен ашауга тиң.

●Рәсми васыятьтә җиде бабаңның имзасы торса, мирас бүлешү туганнар орышына әйләнмәс иде.

●Хокук белгече аңлатма бирә: «Нәселдән килә торган күчемле авыру өчен мирас бүлешү хакында мәккәмә карары кирәкми».

●Артык назлы бала үз әнисе белән әле карында ук идарә итә башлый.

●Балачак сабакларын оныта башлаган ата-ана үзләренең ул-кызларын тәрбияләүдә кыенлык кичерер.

●Елан: «Баланы аякка бастыру җиңел генә бирелми».

●Һәркайсы йорт үзенә хөрмәтле кешеләрнең ешрак чакырылуын теләр, чөнки ул кунак килер алдыннан тоташ җыештырылып куела.

●Үзеңдә берьюлы ике «мин» яшәвен тойсаң,шәхси карашыңны йөрәгең белән киңәшеп билгелә.

●Үзеңне алдау – шайтан файдасына.

●Хәтта сөйкемле сөяк тә тәмуг казанында кайнарга мөмкин.

●Заманча вәгазьдән: «Барлык юллар да Римга түгел, ахыр чиктә ... сират күперенә илтә».

●Үләт-кизү хөкем сөргән чакта күпләр вирус белгеченә әверелер.

●Аллаһның рәхмәте киңдер – ике дөньяга җитәрлек.

●Уң иңбашыңны һавалы рәвештә күтәргәләп йөрсәң, сул яктагы фәрештәң тора-бара кимсенергә мөмкин.

●Ләгыйнь бәндәләр үлеп китә, яман үрнәкләре яшәп кала.

●Тормышта һәммә сынау авыр диеп зарый кылма – алар сиңа гомер белән бергә бүләк ителгән.

●Асылда безнең гомер хаталы инша кебек, аңа хисап көнендә генә билге куелыр.

●Язмыш ханым: «Кыйныймын, димәк, яратам».

●Кара көнгә калдырылган икмәк төшнең яктыларын гына күрер.

● Вәкил Шәйхетдинов һәм Әзһәр Шакиров безнең редакциядә.

● Туфан Миңнуллин портреты.

● Болгардагы Кара пулат яна.

УФАДАГЫ

Казан Кремлендәге «Хәзинә» сәнгать үзәгендә Вәкил Шәйхетдинов күргәзмәсе ачыла, дигән хәбәр ишеткәч тә, аңа атылып бардым. Башкача мөмкин түгел иде, ярамый да. Мондый олуг талант иясе белән танышып китүебез – үзе үк гыйбрәтле бит.

Социаль челтәрләрдә дә эшләү кирәк булгач, без – язучы-журналистлар халкы да камералы телефоннар сатып алган идек. Яңалык постларын күзәтеп барган чакта Камал театрының даһи артисты Әзһәр абый Шакиров портреты хәйран калдырды. Тормышта никадәр мөлаем һәм якты булса, Әзһәр абый әлеге рәсемдә дә шул дәрәҗәдә үк сөйкемле һәм ачык. Портретның авторы Уфа каласында яшәүче Вәкил Шәйхетдинов атлы рәссам икән. Телефон аша бәйләнешкә кердек. Әзһәр абый портретына гашыйк булуыбызны белдерергә ашыгып сүз кушабыз. Ә Вәкил гаҗәеп тәкъдиме белән аркабызга сала:

– Әзһәр абыйны гына түгел, «Мәдәни җомга» газетасын да күптән хөрмәт итәм. Ул портретны Татарстаннан читтә яшереп тоту да ярап бетми сыман. Әгәр күңелегезгә хуш килгән икән, әйдә, мин аны бүләк итим дә, ул сезнең редакция диварын бизәп торсын...

Ничәдер көннән соң Вәкил Шәйхетдинов атлы яңа дустыбызны редакция бинасында кабул иттек. Бәйрәм ялгыз гына үтмәсен дип, аның төп герое Әзһәр абыйны да чакырып куйган идек. Менә шунда иркенләп таныштык та.

Вәкил мин фәкыйрегезнең дә әнисе туган Бүздәк районыннан булып чыкты. Көпәү-Күб атлы сәеррәк исемле авылдан. 1951 елгы. Урта мәктәптән соң Уфадагы сәнгать институтының сынлы сәнгать бүлеген тәмамлаган. 21 яшендә чакта ук Вәкилнең

● «Хәзинә» сәнгать үзәгендә В.Шәйхетдинов күргәзмәсен ачу вакыты.

● Апрель азагында яуган кар.

рәсемнәре төрле күргәзмәләргә куела башлаган. Аннан соң инде СССР, Россия, Башкортстан һәм Татарстанның Рәссамнар берлегенә кабул ителгән. Вәкил үз гомерендә инде 40 тан артык шәхси күргәзмәсен үткәрүгә ирешкән. Аның эшләре Төркия, Болгария, Белоруссия илләре һәм Россиянең дистәләгән шәһәрләре буйлап сәяхәт кылган.

Вәкилнең җаны да, каләме дә туктаусыз эзләнүдә. 1996 елда ул изге Мәккәгә хаҗ кылу бәхетенә ирешкән. Аннан кайткач, билгеле ки, тарихи һәйкәлләргә багышланган һәм дини сюжетларга корылган «Икърар» атлы рәсемнәр сериясен иҗат иткән. 2001 елда Төркиягә сәяхәт кылгач та, андагы бик күп тарихи һәйкәлләрне һәм халык иҗатында гәүдәләндерелгән геройларны үзенең кылкаләм очына алган. Аның борынгы Болгар, Урал-батырга багышланган рәсем серияләре дә бар. Тынгы белмәс рәссам Уфада «Нур» татар театрының яңа бинасын ачкан вакытта да читтән күзәтүче булып кала алмаган, театр диварын «Ләйлә» мозаикасы белән бизәп чыккан. Иң мөһиме – Вәкил үз каләме сайлап алган бер генә темага да битараф түгел, аның күңел күзе һәрбер вакыйганы, һәр һәйкәлне үзенчә итеп күрә һәм тик үзенчә генә итеп сурәтли дә белә.

Менә, Вәкил иҗатындагы бер генә юнәлешне алыйк. Ул 2009 елда татар халкындагы күренекле зыялыларның портретларын иҗат итү эшенә алынган. Рәссамнарыбызның саны белән ничек кенә күкрәк сукмыйк, алар арасында күренекле шәхесләребезне сәнгатьтә гәүдәләндереп калучы бөек Бакый ага Урманче бар иде дә тагын Харис Якупов, Лотфулла Фәттахов, Виктор Кудельки бар иде. Ә соңгы берничә дистә елда татар сәнгатькәрләренең портретларын Эрот Зарипов һәм аеруча Зөфәр Гыймаев кына ару-талу белми иҗат итте. Ни кызганыч, 15 февраль көнендә хөрмәтле Зөфәр ага да арабыздан китеп барды инде, әмма Ходайга мең шөкер, Камал театры диварларында аның



● Бөек Ватан сугышы. Кырлар сагышы.

● Мәккәдәге Гарәфә тавы.

● Разил Вәлиев.

ТАТАР РӘССАМЫ



●Бөек Рудольф Нуриев портреты.



● Әхмәт Лотфуллин.

кулы белән мәңгеләштерелгән дистәләгән артист, режиссер һәм язучыларыбызның портретлары тезелешеп калды. Бүген Татарстанда 4-5 берлеккә аерылган һәм бер-берсенә аяк чалып яшәүче рәссамнар дистәләгән, тик ни аяныч, бөек Урманче яки мәрхүм Зөфәр ага сайлаган иҗат юлы буйлап баручы юк.

Әлеге мактаулы юлны хәзер күрше республикада яшәүче Вәкил Шәйхетдинов кына армый-талмый дәвам итә. Шушы портретлар галереясының бер өлешен ул Казандагы күргәзмәсенә дә алып килгән. Татар халкының талантлы һәм булдыклы икәнен бар дөньяга танытган бөек, горур һәм башбирмәс Рудольф Нуриев портретын сокланмыйча гына карау мөмкин түгел! Даһи Бакый Урманче, Кол Шәриф мәчете фонында йөгән сөймәс чабышкы шикелле сурәтләнгән бөек Туфан ага Миңнуллин алдында баш имичә калу үтә кыен. Ә шулар шикелле үк горур һәм талантлы Мостай Кәрим, Илһам Шакиров, Ренат Таҗетдинов, Рабит Батулла, Равил Шәрәфиев, Дамир Исхаков, Әхмәт Лотфуллин, Разил Вәлиев, Зиннур Мансуров, Марат Кәримов, Вәкилнең үз остазы булган Рәшит Нурмөхәммәтов портретлары...

Гаҗәеп хәл: Яңа ел бәйрәме үттеме, һәр ел саен иҗат берлекләре дистәләгән «бөек әсәр» тәкъдим итеп, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләген эләктерү өчен терсәк һәм өстәл асты сугышлары башлый. Үзебезнең республикада да саф татарча укый-яза белгән татарларның саны биш йөз меңнән дә артык түгел инде. Күрше Башкортстандагы татарларның саны бер миллионнан арта, алар арасында татар халкы – газиз халкым, дип хезмәт куючылары да йөзләгән, меңәрләгән. Халык санын алу әвәрәсе купса, «аһ, Башкортстандагы милләттәшләр татарлыгын саклап калса иде», дип һәр җанисәп барышында ут йотабыз. Әгәр Башкортстандагы татарлар да үз туганыбыз һәм бик кадерле икән, ул Тукай бүләкләрен, Татарстанның орден-медальләрен дә чик аша яшәгән талантларыбыздан кызганмаска иде. Аларның берсе дә – кирәк чакта гына эзләп чаба, ә мич кызуы сүнгәч этеп куя торган табагачлар түгел. Менә, Татарстан Рәссамнар берлеге әгъзасы булып саналучы Вәкил Шәйхетдинов та Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә бик күптәннән лаек!..

«Хәзинә» сәнгать үзәгендә баручы күргәзмәгә Вәкилнең бер йөзгә якын хезмәте куелган. Болгар дәүләте бөек Исламны кабул итүенең 1100 еллыгына багышланган әлеге күргәзмәдә Бөек Ватан сугышының бөтен ачылыгын ярып салган рәсемнәр дә һәм, инде игълан иткәнчә, бөек шәхесләребезне тасвирлаган тулы галерея да бар. Күргәзмә үз эшен 18 мартка кадәр дәвам итсә дә, ул үз теләктәшләрен көтә.

Ә Вәкил дусның Әзһәр абыйны тасвирлаган портретын без күптән Татарстан Милли музей фондына бүләк иттек инде.

Вахит ИМАМОВ.
Автор фотолары.

●Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова.

● Рөстәм хәзрәт Хәйруллин.

Гаилә

Казаныбызны юкка гына Ислам дөньясының төньяк башкаласы дип санамыйлар. Нәкъ менә Казанда Коръәни Кәрим беренче тапкыр типографиядә нәшер ителә башлый. Башкалабыз – мәчетләр шәһәре, дип тә горурлана алабыз. Казанны XVIII гасырда төзелгән борынгы мәчетләр дә, соңгы берничә дистә елда салынган күп яңа Аллаһ йортлары да бизәп тора. Бу юлы Азино микрорайонының яме булган «Гаилә» мәчете буйлап бергәләп сәяхәт итик.

ГЫЙЛЕМ ҺӘМ ТӘРБИЯ ҮЗӘГЕ

«Гаилә» мәчете шәһәребезнең Җәүдәт Фәйзи урамында урнашкан. Бу гыйбадәтханә күз алдыбызда нигез ташлары салынып, күз алдыбызда төзелде. 2013 елның 8 августында, Ураза гаете көнендә ул үзенең ишекләрен ачты. Бу көнгә Татарстан тарихында тагын бер зур вакыйга туры килде – Бөтендөнья Универсиада уеннары ачылды. Мәчет ике спорт корылмасы – Бокс һәм өстәл теннисы үзәге белән «Мирас» стадионы янәшәсендә урнашкан.

«Гаилә» мәчете төзелеше 2007 елда, гыйбадәт йортын төзү өчен җир алудан башланып китә. Бу изге эшне оештырып йөрүче – мәчетнең беренче имам-хатыйбы Хатыйп хәзрәт Бикмөхәммәтов.

Мәчет бинасының гыйбадәт залы берьюлы 300 кешене сыйдыра. Манараларның биеклеге – 33 метр, намаз залы өстендәге гөмбәзе 19 метр биеклектә. Мәчеттә хатын-кызлар залы, никах залы, уку бүлмәләре, кухня, тәһарәтханә, хуҗалык бүлмәләре бар.

Мәчет тиз арада микрорайонның үзәгенә әверелде. Мәхәллә тормышы кайнап тора. Октябрь-май айларында мәчет каршындагы курсларда 300-350 мөселман (өлкәннәр һәм балалар) дин белеме ала. Өч ел белем алганнан соң, гыйлем алучыларга сертификатлар, мөгаллимнәргә рәхмәт хатлары тапшырыла. Балаларның һәрбер каникулында монда дини лагерьлар оештырыла. Каникул буена тәҗрибәле мөгаллимнәр, тәрбиячеләр балаларга дини гыйлем бирә, әдәп-әхлакка, Коръән укырга, төрле кул эшләренә өйрәтә. Шулай ук балалар өчен уеннар,ярышлар, кызыклы очрашулар оештырыла. Моннан тыш, мәчеттә мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен даими «Тәрбияле бала» төркеме дә эшләп килә,анда 25 бала дини белем алу белән бергә мәктәпкә әзерлек курслары да үтә. Ураза һәм Корбан гаете көннәрендә мәчет ишегалдында зур күңел ачу чарасы уздырыла. Бәйрәмдә аларны туйганчы уйнаталар, тәм-том белән сыйлыйлар.

Мәчетнең үз матбугаты да бар – «Мөселманнар» дип аталучы ике телле газета нәшер ителә. Бу басма дини, милли кыйммәтләребезне саклап калу юлында хезмәт итә, ул мәчеткә килүчеләргә бушлай таратыла.

Мәчетнең ишегалдын «Гаилә чишмәсе» бизәп тора. Тирә-як халкын бушка тәмле-йомшак су белән тәэмин итеп торучы бу чишмәне 2017 елда казыдылар. Мәчетнең тирә-ягы декоратив һәм җиләк-җимеш агачлары белән бизәлгән, җәен ишегалды чәчәккә күмелә. Мәчет биләмәсендә балалар өчен заманча зур уен мәйданчыгы ясалды, ял итәргә утыргычлар куелды.

2019 елда мәчет биләмәсендә мәдрәсә – Мөселман дин-мәгърифәт комплексын салу башланды. Тиздән төзелеш-бизәү эшләре тәгәлләнер һәм ул үз ишекләрен ачып җибәрер, иншаллаһ.

ТӨП КАЙГЫБЫЗ - ГАИЛӘ

Бисмилламны әйтеп, мәчет ишеген ачып керәм дә, өс киемнәремне чишенү бүлмәсендә калдырып, йомшак келәмнәр җәелгән баскычлар буйлап икенче катка, имам-хатыйб Рөстәм хәзрәт Хәйруллин бүлмәсенә күтәреләм. Юк, бу мәчеткә баш әйләндергеч затлылык хас түгел, монда барысы да гади, ләкин чиста, уңайлы. Икенче катның диварларын тутырып шәмаилләр элгәннәр. Болар – халыктан җыелган, кешеләрнең әби-бабаларыннан калган шәмаилләр. Югалмасын, сүрәләр язылган шәмаилләр кадерсезләнмәсен дип мәчеткә китерәләр икән. Шкафларда – төрле елларда басылган Коръән нөсхәләре. Болары да халыктан җыелган. Дин әһеленең киемнәрен, элек әби-бабаларыбыз киеп йөргән милли киемнәребезне элеп куйганнар. Бу – үзенә күрә бер музей.

Рөстәм хәзрәт – республикадагы иң абруйлы, танылган хәзрәтләрнең берсе. Ниндидер сорауларга төпле аңлатма кирәк булганда, аңа мөрәҗәгать итәләр, журналистлар сорауларына ул җентекләп җавап бирә, халык белән даими элемтәдә тора. Төп эшләреннән тыш, хәзрәт социаль челтәрләрдә дә зур дәгъват-гыйлем эшчәнлеге алып бара. Аның Инстаграм сәхифәсен 177 мең кеше карап бара, Телеграмм каналына ике мең ярым кеше язылган. Хәзрәт халыктан килгән сорауларга җавап бирә, аңлата. Халык белән эшли белә һәм моны яратып башкара. Моны без «Гаилә» мәчетендә кайнаган яхшы мәгънәсендәге ыгы-зыгыдан да чамалыйбыз. Бер карыйсың, мәчеттә васыятьнамәләр конкурсы оештыралар, халыкны васыятьнамә язарга, яшь буынга үтемле итеп үгет-нәсихәт биреп калдырырга өйрәтәләр. Озак та үтми, шәҗәрә конкурсы оештырып, халыкны тагын гөж китерәләр. Башта боларны эшләргә халыкны өйрәтәсе, аннары килгән йөзләгән эшне тикшерәсе, бәялисе, бүләкләрен тапшырасы да бар бит. Вәгазь кичәләре, «Сөембикә энеләре һәм сеңелләре» бәйгесе дә даими үткәрелеп килә. Мәчетнең кайнап торган көндәлек тормыш мәшәкатьләренә 2019 елда мәдрәсә төзелеше мәшәкатьләре дә өстәлеп китә. Барлык шул эшләрне дә Рөстәм хәзрәт ипләп, көйләп, җайлап алып бара, сөбханаллаһ.

– Рөстәм хәзрәт, абруйлы дин әһеле булып танылганчы, кеше нинди юллар аша үтә?

– Аллаһның рәхмәте белән, минем юлым әллә ни кызык түгел. Бабаларым муллалар иде, төпчек бала булгач, мин аларны күрмәдем. Чыгышым – Бөгелмәдән, бәләкәй чагымда ук әни мәчеткә китерде, анда дәресләргә йөреп, шунда үскән бала. Аннары хәзрәтләрнең юл күрсәтүе белән Казанга килеп, Ислам университетына укырга кердем, аны тәмам иттем. Бер үк вакытта дөньяви белем – педагоглык белеме дә алдым, аспирантурада укыдым. Дини белемемне Болгар академиясендә дәвам иттем. Галимнәр чакырып, Диния нәзарәте курслар үткәреп тора, һәркайсында катнашырга тырышабыз. Казанда укуымны тәмамлагач, мин кире Бөгелмәгә кайттым, анда динебезгә хезмәт иттем. Аннары Казанга, «Гаилә» мәчетенә имам итеп чакырдылар. Мәчет ачылганнан башлап, 9 ел монда хезмәт куям.

- «Гаилә» мәчете – исеменә туры килгән рәвештә, гаиләләр белән чаралар уздыра, эшчәнлеген гаиләне ныгыту, тәрбияләү юнәлешендә оештырадыр, мөгаен?

– Әйе, без мәчетнең исеме җисеменә туры килсен дигән максат куеп эшлибез. Гаиләләр белән эшләргә тырышабыз. Гаилә дәресләре, «Адәм белән Һава» гаилә кору үзәге - барысы да шул юлдагы эшләр. Үзебезнең психолог бар. Гаиләдә кризис башланса, авыр чор башланса, парлар безгә килеп, хәзрәт белән, психолог белән киңәшә ала. Яңа гына «Ышаныч телефоны» ачтык. Чөнки яшьләрнең әниләренә дә сөйли алмый торган мәсьәләләре була, шул чакта аларга дөрес юнәлеш биреп җибәрү кирәк. Кеше безнең телефонга шалтыратып, күңелендә булган авырлыкларны сөйли ала. Максатыбыз – гаиләләргә булышу: дини белем бирү мәсьәләсендә дә, киңәш белән дә, балаларын дөрес итеп тәрбияләү, дини йолаларны үтәргә өйрәтү мәсьәләләрендә дә. Социаль челтәрләрдә дә гаиләнең әһәмиятен, аның проблемаларын чишәргә өйрәтүне беренче урынга куябыз.

– Мәдрәсә төзү нияте ничек башланды?

– Безнең мәчеттә күздән язга кадәр нәни балалардан башлап олы абый-апаларга кадәр әллә ничә төркемдә дин сабагы укыйлар. Укырга йөрүчеләр күп, ә мәчеттә бүлмәләр саны җитешми. Мәдрәсә төзү ихтыяҗы шуннан килеп чыкты. Мәдрәсәнең бер почмагында хәләл кафе да оештырырга ниятебез бар, чөнки халык сорый. Мәдрәсәнең диварлары күтәрелде, хәзер җылылык көйләргә тырышып йөрибез, газ керткәч тә, эчтәге эшләргә тотынабыз. Халыкка рәхмәт, мәдрәсә халык акчасына төзелә. Өметсез шайтан, ди бит, быел безнең юбилей елы, барлык эшләрне тәгәлләп, ачып булмасмы, дибез. Ләкин барысы да килгән сәдакага бәйле, кешеләрдән ярдәм килүгә, бер эшне эшләп куябыз. Ярдәм юк икән, сорыйбыз. Мәдрәсәне инде ике ел төзибез, өченче елга китте менә.

– Мәчет ишегалдында чишмә дә бар, анысы ничек пәйда булды?

–Шушы мәчетне бар итүдә тырышып йөргән, аны төзеткән Хатыйп хәзрәткә зур

«ГАИЛӘ» МӘЧЕТЕНДӘ ЫШАНЫЧ ТЕЛЕФОНЫ ЭШЛИ БАШЛАДЫ

9 февральдән мәчеттә гаиләләргә мораль, психологик ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән ***«Гаилә» ышаныч телефоны»*** *дигән Бөтенроссия проекты эшли башлады. Аның номеры:* ***88002220562****.Теләсә кайсы телефоннан шушы номерга шалтыратып, аноним рәвештә психологик ярдәм алырга була, шалтырату бушлай. Әлеге хезмәт авыр тормыш хәленә дучар булган кешеләргә ярдәм итү, халыкның дини һәм психологик белемнәрен арттыру, кешегә рухи ярдәм, аның үз-үзенә ышанычын арттыру, гаилә мөнәсәбәтләрендәге проблемаларны чишүдә ярдәм итү, суицид һәм көч кулланулардан саклау, авыр хәлдән чыгуда юл күрсәтү, ата-аналарга психологик киңәш бирү, балалары белән мөнәсәбәтләрен көйләү, экстремизмнан саклану, милли хисләрдә таяныч булу максатлары белән оештырылган.*

МӘЧЕТТӘ

рәхмәтләребез булсын. Ул исән чагында мәчетнең нигезен казый башлагач, су чыкты, дип сөйли иде. Хәзрәтне озаткач, аның шушы сүзләре искә төште. Геодезистларны чакыртып тикшерттек, чыннан да якында су бар, диләр. Скважина куеп, чишмә итеп ясатып та куйдык. Теләгән кеше килеп су алырлык итеп ясадык. Суын гел тикшертеп торабыз.

– Мәчеттә нәни балалар өчен төркем дә күптәннән эшләп килә. Югыйсә, күпчелек мәчетләрдә бала-чага тавышын яратып бетермиләр.

– «Тәрбияле бала» төркеме халык соравы буенча оештырылган иде, сабыйларны бик теләп йөртәләр. Мәдрәсә бинасы ачылгач, балалар өчен дә шартлар тагын да яхшырыр, иншаллаһ.

– Хәзрәткә кешеләр күбрәк нинди сораулар белән мөрәҗәгать итә?

– Халыкны дин мәсьәләләрендә тирән фәлсәфи сораулар кызыксындырмый, тәге яки бу очракта нинди дога укырга кирәк, намазны ничек уку дөрес? кебек сораулар. Барлык сораулар да нигездә биш фарызны аңлатуга кайтып кала. Намаз, ураза, зәкят, хаҗ, хәләл ризык мәсьәләләрендәге сораулар. Тирән белемнәрне кулланып җавап бирерлек сораулар сирәк. Халык әле дингә якынаеп кына килә бит. Кемнәрдер турыдан-туры килеп соравын бирергә ояла, шуңа күрә алар өчен социаль челтәрләр ачык, шунда җавап бирәбез. Кызлар маникюр, педикюр, яулык мәсьәләсендә еш сорау бирә. Гаилә парлары еш килә, тагын да килсен. Кайберәүләр соңыннан килеп: «Тегe вакытта мәчеткә кергәндә инде хәзрәт тә ярдәм итмәсә, аерылышабыз, дип кергән идек», диләр, рәхмәтләрен әйтәләр. Андый парларыбыз күп, Аллаһка шөкер, ярдәмебез тисен. Рәхмәт нәзарәткә, безгә медиация курслары үткәрделәр, анда ике кешене дуслаштырырга, араларын җайларга өйрәттеләр, шул белемнәрне дин кануннары нигезендә кулланабыз.

Без халыктан сорауларга, тәкъдимнәргә, идеяләргә шат кына. Ярты елга бер мәчеттә: әгәр мин мәчетнең имамы булсам, тагын нәрсә эшләр идем, дигән анкетага җавап яздырабыз. Аннары шуннан килгән тәкъдимнәрне өйрәнәбез. Әйтик, шул тәкъдимнәр нигезендә китапханә оештырырга ниятлибез, чөнки хәзер китаплар кыйммәт. Ышаныч телефоны да шулай барлыкка килде. Әлбәттә, кешегә игътибар күрсәтеп җиткермәгән чакларыбыз да булгалыйдыр, андыйларга «үпкәләмәгез», дияр идем. Кабат шалтыратыгыз, килегез. Хәзрәтнең дә төрле чагы була, дөнья булгач, мәшәкатьләрне дә хәл итәргә туры килә. Кайчак, күрешкәндә, миннән «Хәзрәт, гаиләгез ничек?» – дип сорыйлар да, мин: «Кайсы гаилә?» – дип җавап бирәм. Күп кеше шуннан хәзрәтнең берничә хатыны, гаиләсе бар икән дип уйларга мөмкин. Минем өчен чыннан да, ике гаилә бар – берсе хатыным, балаларым, икенчесе – «Гаилә» мәчете. Кайчагында, кибеткә баргач, хатын да үпкәләп куя: син иң әүвәл йортка кирәкле әйберне түгел, мәчеткә кирәкле әйберне карыйсың, ди. Гаиләмә игътибар да җитеп бетмидер, таныйм. Ләкин мәчет «гаилә»се зуррак, мәшәкатьләре дә күбрәк.

– Үз гаиләгез дә ишле бит.

– Аллага шөкер, дүрт балабыз бар, олысы кыз һәм өч малай. Кызыма 18 тулып килә, студент, малайлар 9, 4, 1 нче сыйныфларда укып йөри.

...Хәзрәт белән әңгәмәне төгәлләгәч, шыпырт кына икенче каттагы уку бүлмәсенең ишеген ачып карадым. Нурлы йөзле апалар, әбиләр сабак өйрәнеп утыра, яза, Коръән укый. Аларны күреп, йөрәктән рәхәт бер дулкын узды. Икенче бүлмәгә күз салдым - монда да укыйлар, яшьрәкләр. Нинди бәхетле кешеләр, үзләренең рухи үсешләре өчен вакыт таба белгәннәр! Беренче катка төшүгә, балалар тавышы колакка чалынды. Лүзия туташ мине гөр килеп сабыйлар уйнаган зур залга алып керде. Өлкәнрәк балаларга тәрбияче апалары хәреф таныта, язарга өйрәтә. Мәктәпкә тулы әзерлек белән китәләр. Әбигә дә, бәбигә дә, яшьләргә дә якты чырай, җылы караш, түрдән урын «Гаилә» мәчетендә. Килсеннәр генә, монда алар һичшиксез кыйблаларын табачаклар.

СОРАУЛАРГА РӨСТӘМ ХӘЗРӘТ ҖАВАБЫ

– Минем кулга хәрәм юл белән табылган акча керде. Мин ул акчаны хәйрия юлында сарыф итә аламмы?

– Тыелган, хәрәм юл белән табылган акчаны без үзебездә калдырырга тиеш түгел, бирергә кирәк. Ләкин ул акчаны биргән өчен савабы булмаячак. Әйтик, безгә риба юлы белән акча керде, ди. Без, әлбәттә, бу акчаны файдаланырга тиеш түгелбез, без аны кемгәдер ярдәм булсын дип бирергә тиешбез, ләкин моның өчен савап алмыйбыз. Шуңа күрә үзегезне һәм гаиләгезне тыелганнан саклагыз, хәрәм акчаны беркайчан да үзегездә калдырмагыз, гаилә өчен тотмагыз. Хәрәм эшләр белән беркайчан да шөгыльләнмәгез.

– Гөнаһлы нәрсәләр турында уйлау гөнаһка саналамы?

– Фикер үзе әле ул гөнаһ түгел. Ләкин безне Пәйгамбәребез хәерсез уйдан соң гөнаһ эшләнә, дип кисәткән. Ә гөнаһтан качарга тиешбез. Шуңа күрә без хәерсез, гөнаһлы уйлардан да сакланырга тиешбез. Хәерсез уйлар гөнаһлы гамәлләргә юлны ача.

– Авырлы ханымга чәчен кистерергә ярыймы?

– Чәч - хатын-кызның зиннәте. Пәйгамбәребезнең хатыннары да, әбиләребез дә озын толымнар йөрткән. Авырлы вакытта чәчләргә тимәү хәерлерәктер.

– Тәмәке тарткан кешенең намазы кабул буламы?

– Актуаль сорау. Тәмәке тарту – гөнаһ, чөнки бәндә шул рәвешле сәламәтлегенә зыян сала. Кеше тәмәке тарткан өчен гөнаһлы була, ә намазын укыган өчен әҗер савабын ала. Пәйгамбәребез бер хәдис-шәрифтә әйтә, әгәр кем дә булса сарымсак-суган ашаса, ул мәчеткә килмәсен, ди. Чөнки аларның исе фәрештәләрне куар. Тәмәкечедән килгән яман исләр дә фәрештәләрне куа, мөселман кешедән шуңа күрә тәмле, хуш исләр генә аңкып торырга тиеш.

Сәхифәне Эльмира СИРАҖИ әзерләде.



Мәдәни җомга
25 февраль
№ 7, 2022

■Атнаның сәяси мизгелләре

КАЧАКЛАР НИГӘ КАЧА?

Донбасстагы баш күтәргән төбәкләрдә (ДНР һәм ЛНР) 18 февральдә кинәт кенә эвакуация игълан итедле. Гәрчә аңа кадәр сугыш хәрәкәтләре яңартылмаса да, имеш, хәлләр кискен үзгәрүе сәбәпле, Россия гражданнарын ул төбәкләрдән Ростов өлкәсенә эвакуацияли башладылар. Ә алдагы көнне генә Кремльнең матбугат хезмәте Украинаның һөҗүм итү куркынычы турында да белдергән иде. Ә эвакуациягә мөнәсәбәт төрлечә булды. Киев аны Минск килешүләренең җан биргүе дип атады, һөҗүм итәргә җыенмавы турында әйтте һәм Мәскәүне провокацияләрне туктатырга чакырды. Кремльнең матбугат хезмәте исә эвакуацияне белмәмешкә салышты, ә Вашингтон өчен ул игътибарны читкә юнәлтү булып кына күренде. Тик бу дүшәмбегә инде Россиягә 70 меңгә якын качак килгән булып чыкты һәм илнең 30 дан артык субъекты аларны кабул итәргә әзер булуын белдерде. Меңгә якын качакны Казан да кабул итәргә җыена. Ә Донбасста Россия гражданлыгы алырга теләүчеләрнең гомуми саны инде 950 меңгә җиткән.

Эвакуация эчкерсез чара булып күренсә дә, кайбер сәер гамәлләр дә күзәтелде. Әйтик, Россиянең Украина чикләрендә үткәргән планлы хәрби өйрәнүләренең вакыты чыкты, ә гаскәрләр казармага кайтарылмады. Ул гына түгел, Көнбатышны куркыту ниятендә булса кирәк, Россиянең атом-төш баллистик һәм канатлы ракеталары да җибәрүне үз эченә алган хәрби өйрәнүләрен үткәрде. Киевнең Мәскәү белән ачыктан-ачык сөйләшү теләгенә Кремль сөйләшүләрне Донбасс белән үткәрергә киңәш итте. Ә ул арада Кытайда Олимпиада уеннары да тәгәлләнде. Дүшәмбедә Украина тирәсендәге вакыйгалар сөреше гадәти булмаган тизлек алды. В.Путин РФ Иминлек шурасының киңәйтелгән утырышын үткәрде. Аның нәтиҗәләре буенча, телевидение аша халыкка мөрәҗәгать белән чыкты, ДНР һәм ЛНРны тану турында указ чыгарды һәм шунда ук алар белән дуслык һәм хезмәттәшлек турында килешүләр дә имзалады. АКШ дәүләт секретаре Э.Блинкен әле18 февральдә үк БМО КШда ясаган чыгышында, Россия Украинага һөҗүм итү өчен сәбәп кенә эзли, дип белдерде. Ә алдагы көндә генә БМО башлыгы А.Гуттериш Украинада сугыш булмаячак, дигән иде.

Фоат УРАЗАЙ.

Дин өчен сөрелгән татарлар


ЕГО ПРЕВОСХОДИТЕЛЬСТВУ,
ГОСПОДИНУ КАЗАНСКОМУ ГУБЕРНАТОРУ.
РАПОРТЪ.


Докладная записка. Его Превосходительству, Господину Казанскому Вице-Губернатору.

(Дәвамы. Башы 6нчы санда).

Бу исемлек буенча эшләгәндә каршылыклар күп очрады. 1867-1868 елларда Казан губернасыннан Турухан краена сөрелгән татарларның көчләп чукындырылган мәкруһлары – урыс исем-фамилиясе астында, мөселманнары – үз исемнәре белән киткән. Патша хөкүмәте ачкан «Эш»тән күренгәнчә, Тәфкил аганың бабасы эләккән исемлектә унбер кешедән нибары берсенең генә татарча исеме язылган – Салтыган мулласы Таҗетдин хәзрәт Мөхәммәдъяров. Калганнар барысы да урысча – Гурий Васильев, Никифор Николаев, Степан Андреев һ.б... Бу урыс-христиан исемнәре астында кайсы татарларның газиз үз исемнәре сулкылдый икән? Тәфкил абый бу исемлектән үзенең бабасы Мөхәммәтсабит Шәрәфетдиновны эзләп тапкан – ул Василий Иванов исеме астында Себер киткән. Урыс астындагы тагын өч татарның мулла кушкан исемнәре ачыкланган: Иван Петров – Әбраретдин Рәхмәтуллин, Антон Иванов – Габделхәбир Зиннәтуллин һәм Николай Никитин – Хәкимулла Талипов. Мөгаен, Себердә дә, рәсми документларда, алар урыс-христиан исеме белән йөргәндер, ә үзара – татар-мөселманча...

Ул елларда Себергә көчләп чукындырганнан соң яңадан исламга кайткан татарлар һәм чукындырылмаган, әмма чукындыруга каршы булган мөселман-татарлар сөрелә. Мәсәлән, 1987 елның 6 мартында Тәтеш өязеннән Турухан краена крестьян татарлар Хәмидулла Габдрахманов, Мөхәммәтша Зиннәтдинов, Әбдүш Усманов һәм Фәтхулла Абдуллов сөрелә. Бу мөселман-татарларның исемнәрен Красноярск архивыннан килгән исемлекләрдә дә очратырга була. Шулай ук бу исемлекләрдә, Казан губернасыннан тыш, Түбән Новгород, Вятка, Әстерхан, Сембер, Иркутск, Енисейск губерналарыннан, хәтта Якутскидан сөрелгән татарларның да исемнәре теркәлгән. Моннан тыш, мәчеткә йөрүчеләр арасында Томск, Енисейск мещаны, дип язылган мөселманнар да бар, болары патша хезмәтендә булучы яки җирле сәүдәгәр татарлар булырга мөмкин.

1888 елның 10 ноябрендә тутырылган исемлектә Енисейскида яшәүче һәм андагы мәчеткә йөрүчеләрнең исемлеге теркәлгән, алар 200 кеше! Исемлеккә имам Әхмәтсафа хәзрәт Таҗетдинов үзе кул куйган, казна мөһере басылган. Кайбер исемлекләрдә исем-фамилияләр кабатлана, яңалары да бар, искәрмә буларак, кайберләренең Енисейскида үз өйләре яки квартирасы барлыгы да әйтелгән, поселенец икәнлеге ассызыкланган. 1884 елның 5 октябрендә Енисейск шәһәрендә Җәмигъ мәчет салырга карар иткән мөселман-татарлар 92 кеше, аларның бер өлеше имзаларын гарәп имлясы белән куйган. Казан губернасыннан сөрелгән татарларның бер өлеше бу исемлекләрдә «Енисейск губернасы поселенецы», дип теркәлгән булырга охшый, чөнки таныш фамилияләр очрый. Бу кешеләрнең инде Казан төбәге белән кендекләре өзелгән, ул тарафка юллар гомерлеккә ябылган, алар инде шушы Турухан крае кешеләре булып исәпләнә...

1884 елда, Енисейскида Җәмигъ мәчет салу турында карар кабул итүчеләр арасында Фәтхулла Абдуллинның да фамилиясен күргәч, мин тетрәнеп киттем! Ул 1888 елгы исемлектә дә бар, анда «Туруханск крайдагы поселенец», дип язылган. Бу бит шул Фәтхулла, Зөя-Свияжск төрмәсендә ятканда, хатыны Гарфиҗамал аңа, «Чукына күрмә, Фәтхулла җаным, әгәр дә сине Себергә җибәрәләр икән, мин дә синнән калмыйм, синең белән бергә барам...», дип хат язган, ул да Казан архивында саклана:

«Сез ки хәләл җефетем Фәтхуллага без хәләл хатыныңнан – Гарфиҗамалдан күптин-күп сәламнәремне язам. Фәтхулла, җаным, үтенеп сорыйм синнән, Гайфулла кебек үзеңне чукындырып хурлыкка кала күрмә. Бөтен авыл халкы сиңа кяфер дип әйтер. Битеңә төкерерләр. Әгәр син урыс буласың икән, ул вакытта бу якты дөньяда чыннан да ни өчен яшәргә? Бу якты дөньяда яшәүнең кызыгы калмый. Әгәр дә сине Себергә җибәрәләр икән, мин дә синнән калмыйм, синең белән бергә барам. Артыңнан калмыйм. Аллаһы Тәгаләнең кодрәте зур, ташламас. Ичмасам, кызыбыз авыл халкы каршысында хур булмас. Минем хатыным бар дип әйт. Өмет баглыйм сиңа, Фәтхуллам!» (ТР МА. Ф.1, тасвирлама 3, саклау берәмлеге 228, бит- 111.)

Тәтеш өязе татары Фәтхулла Абдуллов 1867 елның 6 мартында сөргенгә сөрелә. Димәк, Гарфиҗамал сүзендә торган, ире артыннан Себергә чыгып киткән! Чөнки бер документта Фәтхулла Абдуллин «поселенец» дип теркәлгән, ә ул гаиләң янында булганда гына мөмкин хәл була. Бу татар хатынының иман ныклыгына, батырлыкларына, тугрылыкларына таң калырлык! Менә кемнәр саклап калды ислам динен һәм татар милләтен иң авыр елларда – татар хатыннары! Ирләренә – терәк, милләткә үрнәк алар – иман хакына, гаилә хакына үз теләкләре белән гомерлеккә Себергә киткән татар хатыннары...

Безнең милли һәм дини каһарманнарыбыз – менә шушы кешеләр. Татар халкы 1100 ел буе ислам динендә, милләт булып яши икән, без менә шушындый фидакяр затларга бурычлы, аны без белгән һәм белмәгән каһарманнар саклап калды. Догаларыбыз һәм мактауларыбыз аларга булсын!..

Фәүзия БӘЙРӘМОВА,
язучы, тарих фәннәре кандидаты.

Татар ничек вакытны иялләштергән

Хәзерге күзлектән карасак, иң җитешмәгәне – вакыт. Нигә тәүлектә артык сәгатьләр юк икән? Әмма бу вәзгыять әллә ни иске дә түгел. Вакытны бик сузмыйча, сәгатьләр һәм минутлар санап йөри башлау нибары XIX гасырда күренә башлый. Чөнки дөньялар үзгәрә, эшләгән эшләр һәм кешеара мөнәсәбәтләр катлаулана. Бу чорда Европадан матур-матур сәгатьләр дә кайта, Россиядә дә сәгать төзәткән осталар саны арта.

Кайберәүләр, әлбәттә, сәгатьләр булса да, әүвәлгечә, вакытны сузып яшәүне хуш күргән. Бу хакта тарихчы һәм мулла Шиһабетдин Мәрҗани (1818-1889), үзенә генә хас үткер теле белән болай дигән:

«Безнең халкымыз руслардан бик күп бозык гадәтләр алганлары хәлдә ике төрле бик гүзәл гадәтне ала алмады. Бу гүзәл гадәтләрнең бере – сәгатьне тугры вә дөрест йөртү вә икенчесе дә дәгъвәтле мәҗлесләргә сәгать вә дәкыйкасендән кичекми хазир булудыр».

Ягъни вакытында гына чакырган урыннарга килә алмыйлар, гел соңлап йөриләр, дип шелтәләгән. Төрле-төрле сәгатьләр чынлап та Мәрҗани яшәгән чорда ук – XIX гасыр уртасында – киң тарала. Бигрәк тә сәүдәгәрләр ярата аларны. Казакин кесәсеннән күренеп торган алтын сәгать чылбыры уңыш казанган татар кешесенең мөһим атрибутына әйләнә.

1884 елда Уфа губернасындагы Бәләбәй шәһәренә барып чыккан публицист Леонид Пиглевский бу хакта кызыклы язма калдырган. «Шәһәр мәйданында бер мөселманга тап булдым, – дип яза ул. – Бай гына киенгән, билендә – көмеш бизәүле кушак, алтын сәгатенең чылбыры да күренеп тора. Алдан белеп торам инде - хәзер үзен «казанский купца» дип таныттачак миңа». Шулай танытса да бу кеше, әлбәттә, Бәләбәй бае була. Әмма «казанский купца» атамасы һәм алтын сәгать чылбыры бергә йөргән.

Әгәр шул чордагы татар байларының йортына керсәк, һәр җирдә сәгатьләр күрер идек: идәннән түшәмгә җиткән иң зурларын да, өстәлгә куелган бераз кечкенәрәкләрен һәм диварга эленгәннәрен дә. Матур тавышлы сәгатьләр йорт җиһазы гына булмаган, ә кантурларда да очраган. Мәсәлән, Оренбург байлары Хөсәеновларның кантурында Швейцариядән кайткан зәвыклы сәгать вакыт күрсәткән.

Казан сәүдәгәре Мөхәммәтшакир Казаков шулай ук Швейцария сәгатьләрен яраткан һәм бай коллекция җыйган. «Бар бүлмәсе данлыклы швейцар фирмалары чыгарган сәгатьләр белән бизәлгән иде», – дип искә алганнар аны оныклары.

●Кәрим Тинчурин сәгате.

●Гаяз Исхакый сәгате.

●Тукай музеендагы борынгы сәгать.

Муллалар «музыка – хәрам» дип йөргән заманда, бай татар йортларындагы зур сәгатьләр матур тавышлары белән дә ямь биреп торган. Бер-бер артлы суккан сәгатьләр тавышы (моның өчен махсус рәвештә вакытларын төрлечә күрсәткәннәр хәтта) үзенчәлекле көй кебек күренгән хуҗаларга. Мулла кушмаса да, сәгать чыгарган музыканы тыңлаганнар.

Юкка гына сәгать механизмнары төзәткән остаханәләрдә соңрак таралган музыка тартмаларын («Стелла», «Мирра», «Аристон» фирмалары) төзәтмәгәннәр – барысының да механизмы бер. Казандагы Печән базарында башта Гариф Минкин, аннары аның шәкерте Гыйләҗетдин Сәйфуллинның шундый остаханәләре эшләгән.

Мәсәлән, Казан сәүдәгәре Фәттахетдин Гобәйдуллинның йортында 300 сумлык «инглиз музыкаль сәгате» булган, тагын бер шундый сәгатьнең бәясе 150 сумга җиткән. Ә ике музыка тартмасы нибары 10 һәм 3 сумга сатып алынган була. Һичшиксез, бу йорт хуҗасының төгәл вакыттан да бигрәк, музыканы яратканы күренеп тора.

Шулай да, сәгатьләр, беренче чиратта, вакытны «иялләштерү» өчен кирәк була. Сәүдә иткән әфәнделәр бер урында тормаган, шәһәрдән шәһәргә йөреп, нәрсәдер саткан яисә сатып алган. XIX гасырда инде атлар җигеп йөрү белән генә чикләнмиләр, тизрәк һәм җайлырак транспорт төрләре дә барлыкка килә. Ә пароход һәм поездлар – барысы да расписание буенча йөри бит әле. Менә нигә кирәк вакытны төгәлләштерү, сәгатьләргә карап яшәү... XX гасыр таңында протестантлар арасында әллә кайчан таралган «вакыт – акча» дигән фикернең татарча вариантлары да күренә башлый. Мәсәлән, мәгърифәтче Ризаэтдин Фәхретдин 1911 елда язылган «Нәсыйхәтләр»ендә «вакыт» төшенчәсенә дә аерым кагыла, аның кадерен белгән кешене мал тота белүче белән чагыштыра.

«Вакытын сарыф итә белгән кеше малын да сарыф итә белер, ягъни бер минут вакытын буш җиргә сарыф итмәгән кебек, бер тиен булсын – акчасын да урынсыз җиргә җибәрмәс, – дип яза ул. – Шуның өчен вакытыгызны вә малыгызны әрәм итмәгез, алдан күрүчән булыгыз, ахмак кешеләр кебек акчагызны, дөнья вә ахирәттә файдасы өметле булмаган әйберләргә сарыф итмәгез, вакытыгызны да исраф итмәгез».

Бу нәсыйхәтләр балаларга бирелә. Аңлашыла ки, үскән буынны Ризаэтдин хәзрәт вакыт кадерен белеп яшәргә үгетли. «Вакыт – акчадыр, гафил улма – качадыр» дигән язма Казанда 1910 елларда чыгып килгән «Кояш» газетасы редакциясендә эленеп торган. Моны хәзерге татар теленә җайлаштырсак, «Вакыт – акчадыр, йоклама – качадыр» дип аңлатырга була. Бу редакциянең иң билгеле журналисты – язучы Фатыйх Әмирхан.

XX гасыр башында төрле-төрле сәгатьләр, шул уңайдан чылбырлы кесә сәгатьләре дә, сәүдәгәрләргә генә түгел, ә башка катлам вәкилләренә дә хас була. Мәсәлән, Татарстан Милли музеенда әдип Кәрим Тинчуринның өстәл сәгате, ә Гаяз Исхакыйның кесә сәгате саклана. Бәлки, талантлары белән сокланган, рәхмәтле китап укучыларыннан һәм тамашачылардан бирелгән бүләк сәгатьләредер ул? Әнә Габдулла Тукайның «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» поэмасында да бит бәхетле Кисекбаш чиксез рәхмәт хисләрен батыр Карәхмәткә кыйммәтле сәгать бүләк итеп белдерә:

«Пәһлеванга бирделәр алтын сәгать, Чылбыры юк, белмимен, нидер сәбәп…»

XX гасыр башындагы фотосурәтләргә карасак, чылбырлы кесә сәгатьләрен ханым вә туташларда да күрергә мөмкин. Вакытны карап йөрү аларга да кирәк: уку йортларымы, китапханәме, сәүдә урыннарымы, театр яисә әдәби кичәме – барысының да эш сәгатьләре бар.

Ә шәһәр фольклорында бу чорда сәгать гел качып барган вакытның символына әйләнгән. Шул замандагы иң билгеле татар халык җырларының берсе дә бит «Сәгать чылбыры». Сәгать чылбырын югалткан герой дөнья аһ-зарына, вакыт узганына моңланса да, әле һаман югалтканы табылыр, дип өметләнә:

«Әй, югалттым сәгать лә чылбырым, Күрмәдеңме, сылуым, былбылым?»

Лилия **ГАБДРАФИКОВА.**

Айга карама кырын

Халык медицинасы чаралары белән дәваланугa керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

26 февраль (шимбә). ***Рәҗәб аеның 25 нче көне. 26 нчы Ай тәүлеге. Ай Кәҗәмөгез йолдызлыгында,4.55 сәгатьтә калка, 10.49 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 10.29 сәгать.***

Һәртөрле вәсвәсәләргә бай көн. Әйләнә-тирә дөньяны кабул итү кискенләшә, тәэсирләнүчәнлек арта, чит кеше йогынтысына бирешүчәнлек көчәя. Килешүләр төзү уңышлы. Нерв системасы, аяк зәгыйфь. Балык, мүк җиләге, сөт ризыклары ашау файдалы.

Грипптан лимон саклый

Гриппны кисәтү өчен, 2 лимонның төшләрен алып, кабыгы белән вак угычтан уалар, издерелгән 1 баш сарымсак, 1 л кайнар су кушып, көн буе төнәтәләр, сөзәләр, суыткычта саклыйлар. Иртән ач карынга 1 аш кашыгы кабалар.

27 февраль (якшәмбе). ***Рәҗәб аеның 26 нчы көне. 27 нче Ай тәүлеге. Ай Сукояр йолдызлыгында,5.51 сәгатьтә калка, 12.03 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 10.34 сәгать.***

Бу көннәрдә организм хәлсез, шунлыктан күбрәк йоклау файдалы. Нерв системасы, сизү әгъзалары зәгыйфь. Кан һәм лимфа авырулары кискенләшергә мөмкин. Кан басымын контрольдә тоту сорала.

С витамины кирәк

Ай кими барган көннәрдә энергия актив тотыла, димәк, дәрт өстәр өчен С витаминына бай ризыклар - киви, брокколи, татлы борыч, гөлҗимеш, цитрус җимешләре ашау файдалы. С витаминына ярдәмчеләр - биофлавоноидлар да кирәк, әлеге матдәләр яшел чәй, алма, суган, помидорда күп.

28 февраль (дүшәмбе). ***Рәҗәб аеның 27 нче көне. 28 нче Ай тәүлеге. Ай Сукояр йолдызлыгында,6.27 сәгатьтә калка, 13.32 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 10.38 сәгать.***

Айның иң яхшы көннәреннән берсе. Энергетикасы бик уңай. Көтелмәгән очрашулар берсеннән-берсе кызыклырак булачак. Хисләр тернәкләнә, аралашу теләге уяна. Сизү әгъзалары, аеруча күзләр зәгыйфь. Кан басымын контрольдә тоту зарур. Яңа Ай туарга ике генә көн калып бара, караңгы, Айсыз төннәр күңелгә шом сала. Организмны чистарту, ач тору уңай нәтиҗә бирә.

1 март (сишәмбе). ***Рәҗәб аеның 28 нче көне. 29 нчы Ай тәүлеге. Ай Сукояр йолдызлыгында,6.10 сәгатьтә калка, 15.06 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 10.42 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Бернинди вәгъдәләргә дә ышанырга ярамый. Безләр системасы, кан тамырлары, эчәклек зәгыйфь. Үзеңне үпкәләткән кешеләрне кичерү зарур.

Сарымсак мае

1 баш сарымсакны чистартып, уып, согын чыгаралар, шуңа 1 стакан чистартылмаган көнбагыш мае кушып, 1 тәүлеккә суыткычның аскы киштәсенә куялар. 1 чәй кашыгы сарымсак маена 1 чәй кашыгы лимон согы кушып, көненә

(**Дәвамы 18 нче биттә**).

Айга кырын карама

3 тапкыр ашарга 30 минут кала эчәләр. Дәва курсы 1-3 ай. Сарымсак мае баш миендәге тамырларны кысылудан саклый, тын кысуны бетерә.

2 март (чәршәмбе). ***Рәҗәб аеның 29 нчы көне. 30 нчы, 1 нче Ай тәүлекләре. Ай Балыклар йолдызлыгында, 7.06 сәгатьтә калка, 16.38 сәгатьтә бата. 20 сәгать 34 минуттан яңа Ай. Көн озынлыгы 10.47 сәгать.***

Тәүбә итү, гармониягә ирешү көне. Иҗат белән шөгыльләнү, айлык план төзү яхшы. Өйләнә-тиранә дә, үз хисләреңне дә кабул итү кискенләшә, тәэсирләнүчәнлек, интуиция арта. Баш һәм йөрәк зәгыйфь. Арып-талганчы эшләргә, артык кайнар ризык ашарга ярамый. Төрле исләргә аллергия килеп чыгарга мөмкин.

Йөрәккә дәва

100 г инҗир, 1 лимон, 1 стакан әстерхан чикләвеген иттарткычтан чыгарып, 8 аш кашыгы бал кушалар, яхшылап болгаталар, пыяла банкага салып, 3 көнгә суыткычка куялар. Аннары 1 атна буе иртән һәм кичен 1 әр чәй кашыгы, аннары 1 әр аш кашыгы кабалар. Катнашма беткәч, 1 ай ял итәләр, аннан соң тагын кабатларга була.

3 март (пәнҗешәмбе). ***Рәҗәб аеның 30 нчы көне. 2 нче Ай тәүлеге. Ай Балыклар йолдызлыгында,7.18 сәгатьтә калка, 18.07 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 10.51 сәгать.***

Яңа туган Ай Җир белән Кояш арасында, үзенең караңгы ягы белән Җиргә караган. Ай идарә итә торган һәрнәрсә – хисләр, кәеф, хәтер, кан басымы зәгыйфь. Кан басымы болай да түбән булган гипотониклар өчен бигрәк тә авыр вакыт. Бу чорда укуда уңышлар, тиз савыгу, югары эшчәнлеккә өметләнергә ярамый. Ашаганда талымлы булу хәерле. Аралашуны чикләү зарур.

Аяк тиресе ярылганда

250 г вакланган имән кайрысын 3-4 л суда 30 минут кайнаталар, шулкадәр үк су кушып, аякларны тыгып утыралар, яки компресс куялар. 30 г каз үләнен (лапчатка) ярты литр суда пешереп, яки 50 г вакланган үләнне 1 стакан зәйтүн маенда 20 көн буе төнәтеп, аяктагы ярыкларга сөртәләр. Яисә тырнак гөл төнәтмәсе белән дәвалаланалар.

4 март (җомга). ***Шәгъбән аеның 1 нче көне. 3 нче Ай тәүлеге. Ай Кучкар йолдызлыгында,7.27 сәгатьтә калка, 19.31 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 10.56 сәгать.***

Бик актив көн, хәвеф-хәтәр инстинкты, агрессия белән бәйле. Бүген чирләп китү ихтыяр көченең җитәрлек булмавын күрсәтә. Күзне арытмаска кирәк.

Итле салат

Ярты килограмм яхшы сыйфатлы сыер итен аз гына тоз салынган суда дәфнә яфрагы, суган, кара борыч белән бергә 1 сәгать пешерәләр, суытып, саламлап турыйлар. Ике-өч зур суганны боҗралап турыйлар. Маринад әзерлиләр: 50 миллилитр кайнатып суытылган су, 2 аш кашыгы шикәр, 1,5 чәй кашыгы тоз, 5 аш кашыгы шәраб серкәсе, 0,5 чәй кашыгы төелгән кара борыч, 5 аш кашыгы чистартылган көнбагыш маен кушып болгаталар. Зур тирән савытка бер катлам ит тезәләр, аннары – суган катламын җәяләр, маринад салалар, аннары шулай катлам-катлам тутырып бетергәч, 8 сәгать маринадланырга калдыралар. Табынга куйганда, яшел тәмләткеч үләннәр, анар төшләре белән бизиләр.

Телебезнең актуаль мәсьәләләре

Бу атнада дөньяның барлык халыклары Туган телләр көнен билгеләп үтте. Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре дә шушы уңайдан академиянең кече залында «Татар лексикографиясенең актуаль мәсьәләләре» дигән темага «түгәрәк өстәл» утырышы уздырды. Җыенда Татарстан Президенты Аппараты, Дәүләт Советы, Казан, Чаллы шәһәрләренең фәнни һәм белем бирү оешмалары, Татарстан китап нәшрияты, көндәлек матбугат вәкилләре катнашты. Институт галимнәренең саллы эшчәнлеге тел белеме белән бәйле. Бирелдәге 10 бүлекнең өчесе – гомуми лингвистика, лексикология, диалектология бүлекләренең фәнни хезмәткәрләре турыдантуры тел мәсьәләләре белән генә шөгыльләнә. Шуңа да утырышта Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының татар лексикографиясе үсешендә әйдәп баручы оешма булуы ассызыкланып, хәзерге татар лексикографиясенең үсеше һәм сүзлекләргә ихтыяҗ, филологик сүзлекләр төзүдә төп хәл ителергә тиешле мәсьәләләр тикшерелде.

Әлбәттә, институт телебезнең байлыгын, диалектларны, терминнарны өйрәнү өлкәсендә зур эшчәнлек алып бара. Шушы максатта күп кенә фәнни хезмәтләр әзерләнеп нәшер ителә. Әйтик, сигез томлык «Татар әдәбияты тарихы», «Хәзерге татар теле: функциональ һәм структур классификация мәсьәләләре», «Татар грамматикасы», өч томлык «Татар лексикологиясе» дигән фундаменталь хезмәтләр – шундыйлардан.

Соңгы биш елда Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлеге галимнәре төзегән егермедән артык сүзлек дөнья күргән. Бу – зур байлык. Институт директоры урынбасары Олег Хисамов мондый хезмәтләрнең күбесенең төрки дөньяда беренче тапкыр дөнья күрүен искәртте. Институтта шулай ук татар русча-татарча татар антропонимнары, ягъни кеше исемнәре һәм фамилияләре сүзлеген туплау буенча да эш алып барылган. ЗАГС хезмәткәрләре үтенече буенча эшләнгән хезмәт – тәмамлану алдында.

Түгәрәк өстәл утырышында кайбер актуаль мәсьәләләр дә күтәрелде, көндәлек матбугатта, төрле эш кәгазьләрендә бер үк сүзләрнең төрлечә язылуы искәртелеп, орфографик сүзлек әзерләп нәшер итү кирәклегенә басым ясалды. Моннан тыш дәүләт дәрәҗәсендә тәрҗемәчеләр әзерләү дә сорала.

Институт белгечләре төзегән сүзлекләрнең электрон варианты Татарстан Фәннәр академиясенең сайтына урнаштырылып барыла. Бүген анда төрледән-төрле 58 сүзлек белән танышырга мөмкин.

Сөембикә КАШАПОВА.

Әдәбият энциклопедиясе

Татарстан Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре «Татар әдәбияты тарихы» дип исемләнгән 8 томлы зур хезмәтне нәшир итүне тәмамлады. Энциклопедик хезмәт татар әдәбиятының борынгы чорыннан алып XXI гасыр башында иҗат ителгән әдәби әсәрләрне һәм аларның авторлары иҗатын анализлауны үз эченә ала.

Узган атнада Татарстан Язучылар берлеге бинасында әлеге 8 томлык җыентыкны тәкъдир итү кичәсе үтте. Аңа, әлбәттә ки, әдәби энциклопедия өчен фәнни хезмәтләр язган галимнәр, бер төркем язучылар һәм матбугат вәкилләре чакырылган иде. Әүвәл энциклопедия төзелү принциплары һәм әдәби үсеш этаплары турында Г.Ибраһимов исемендәге институт, Фәннәр академиясе һәм Федераль университет галимнәре Д.Заһидуллина, Ә.Закирҗанов, Р.Рахмани, Х.Миңнегулов, Ф.Галимуллин, Ф.Яхин, Р.Сверигин, язучылар арасыннан Л.Лерон һәм В.Имамов чыгыш ясады. Йомгаклау сүзләрен галимнәр һәм язучылар исеменнән Д.Заһидуллина һәм Р.Зәйдулла ирештерде.

Мәк тамаша заллары чакыра

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

24 февраль – 3 март – Камал театрының Чаллыда гастрольләре.
25 февраль – 11.00 – «Сүнгән йолдызлар» (К.Тинчурин).19.00 – «Мәхәббәт FM» (И.Зәйниев).
26 февраль – «Энергетик» мәдәният сараенда 12.00 – «Хуш, авылым» (А.Җаббаров). 18.00 – «Сәфәр» (А.Шакиров). 18.00 Орган залында – Р.Яхинга багышланган концерт. Чаллы театры бинасында 18.00 – «Хуш, авылым. Хыял» (А.Җаббаров).
27 февраль – «Энергетик» мәдәният сараенда 12.00, 18.00 – «Сәфәр»(А.Шакиров). Чаллы театры бинасында 12.00, 18.00 – «Хуш, авылым. Хыял» (А.Җаббаров).
28 февраль – Чаллы театры бинасында 12.00, 14.00 – «Шомбай, бүре һәм малай» (Ф.Җиһанша). «Энергетик» мәдәният сараенда 19.00 – «Сагынырсызмы?» (А.Шәйдуллин).
1 март – Чаллы театры бинасында 12.00 – «Шомбай, бүре һәм малай». – (Ф.Җиһанша). «Энергетик» мәдәният сараенда 19.00 – «Өйләнәм tat» (И.Зәйниев). Г.Камал театры бинасында – «Казан» бию ансамбле концерты.
2 март – Чаллы театры бинасында 12.00 – «Шомбай, бүре һәм малай (Ф.Җиһанша). 19 00 – «Томан» (Г.Сәгыйтова). «Энергетик» мәдәният сараенда 12.00, 19.00 – «Өйләнәм.tat» (И.Зәйниев). Г.Камал театры бинасында 19.00 – «Казан» бию ансамбле концерты.
3 март – «Энергетик» мәдәният сараенда 12.00, 19. 00 – «Бию пәрие» (И.Зәйниев).

М.ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ҺӘМ БАЛЕТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

26, 27 февраль – «Корсар» (А.Адан).
2, 3 март – «Баядерка» (Л.Минкус).

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

25 февраль – 15.00 – «Син бит минем бергенәм» (И.Мәхмүтова). 18.30 – «Әзелгән яфраклар» (Р.Габделхакова).
26 февраль – «Өч аршын җир» (А.Гыйләҗев).
27 февраль – «Сүнгән йолдызлар» (К.Тинчурин).
1 март – Классик музыка шедеврлары концерты.
2 март – «Эх, алмагачлары!» (Ш.Фәрхетдинов).
3 март – «Туй алдыннан» (Х.Вахит).
4 март – «Полиционер» (И.Зәйниев).

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ

25 февраль – «Ак чәчәкләр кебек...» (Р.Мухина).
26 февраль – «Мио, минем Мио!» (А.Линдгрен).
27 февраль – 13.00 – «Бәхетле көнем» (Е.Гороховская). 18.00 – «Кичер мине, әнкәй» (Р.Батулла).
2 март – «Алтынч[ае]ч» (Л.Янсуар, Р.Гарипова).
4 март – «Шәй-бу! Шай-бу! (К.Кәримов).

«ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ

26 февраль – зур залда - «Сказка о царе Салтане» (А.Пушкин). Кече залда – «Адәмнәр» (Г.Ибраһимов).
27 февраль – 10.00 – «Один день из жизни улитки» (Ольга, Юрий Устюговлар). 12.00, 14.00 – «Муха-цокотуха» (К.Чуковский). 13.00 – «Мактанчык әтәч» (Аманулла).
2 март – «Приключения барона Мюнхгаузена» (Р.Э.Распе).
3 март – 11.00, 13.30 – «Страна чудес Алисы» (Л.Кэрролл).
4 март – 11.00 – «Страна чудес Алисы» (Л.Кэрролл). 19.00 – «Ханума» (А.Цагарели).

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

25 февраль – «Спящая красавица» балеты.
26 февраль – Саксофончылар квартеты концерты.
27 февраль – А. Шутиков җитәкчелегендәге Татарстан дәүләт халык музыка уен кораллары оркестры концерты.
28 февраль – А.Фәйзрахманов җитәкчелегендәге дәүләт фольклор музыкасы ансамбленең «Хәрәкәттә-бәрәкәт» дип исемләнгән концерты.
1 март – Динә һәм Рафаэль Латыйповлар концерты.
2 март – Дагыстаннан «Лезгинка» дәүләт академик бию ансамбле концерты.
3 март – «VIVA» вокаль төркеме концерты.
4 март – 15.00 – «Гарри Поттер и затерянный лес» спектакле. 19.00 – «Мастер и Маргарита» спектакле.

С.СӘЙДӘШЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ЗУР КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

2 март – Неоклассика шедеврлары. Музыка һәм кино. Наталья Железных ансамбле чыгыш ясый.
4 март – Татарстан Республикасы дәүләт камера хорының «Моя прекрасная леди» дип исемләнгән концерты.

«Арча батырлары»н сурәтлим

Казан рәссамы, офорт остасы, Россия һәм Татарстан Рәссамнары берлеге әгъзасы Рәшит Гаимов гомер буе белем бирә. Ул – Казанның төрле уку учреждениеләрендә кырык елдан артык сынлы сәнгать нигезләрен укыткан талантлы педагог. Р.Гаимов бүген дә мөгаллимлек эшен дәвам итә: Казанның 11 нче балалар музыка мәктәбенең сынлы сәнгать бүлегендә укучыларны рәсем сәнгатенә өйрәтә.

Булачак рәссам 1951 елны Казанда туган. 2 нче сәнгать мәктәбен, Казан сынлы сәнгать училищесын, Чабаксарның И.Я.Яковлев исемендәге дәүләт педагогика институтын тәмамлаган. Шушы институтта укыган чакта ук, ул офорт техникасы белән кызыксынып китә. Талант иясе 1979-1993 елларда, 14 ел буе Химиклар мәдәният сарае карамагындагы халык сынлы сәнгать студиясендә кечкенә балаларны һәм олыларны рәсем ясарга өйрәтә. Бу студия халык иҗаты фестивальләре нәтиҗәсе буенча дүрт мәртәбә беренчелек яулый! Рәшит Хәмит улының уңышлы хезмәте СССР Рәссамнар берлеге дипломы белән бүләкләнә. Рәссам 1991 елда татар халкының тарихи героик-эпик шигъри «Идегәй» дастанына мөрәҗәгать итеп, офорт ысулындагы сериясен иҗат итә башлый. Алтын Урдадагы кискен көрәшне, тарихи шәхесләр Аксак Тимер, Туктамыш хан, Идегәй әмир һәм башка каһарманнарны теләп ясаган. Аннары «Казан ханлыгы», «Бөек Ватан сугышы» серияләренә алынган. Ул катлаулы, металлны кислота белән ашатып гравировка ясалучы тирән басма техникасында – акватинта ысулында иҗат итүне сайлап алган. «Гомумән, мин – «Идегәй» иллюстрацияләрен беренче булып басма графикада, офортта иҗат итүче булып саналам, – ди Рәшит Хәмит улы. – Һәм тарихи вакыйгаларны сурәтләү жанры буенча да Казан ханлыгы тарихын, андагы хакимлек рәвешен, казанлыларның шул чордагы көнкүрешен, кала риваятьләрен офорт манерасында иҗат иткән беренче рәссам».

2007-2013 елларда рәссам Казан илкүләм тикшеренү технология университетының дизайн кафедрасы доценты буларак хезмәт куя һәм шушы чорда пластик анатомия буенча өч укыту-методик әсбаб әзерләп бастыра. 2011-2012 елларда Мәскәү В.И.Суриков исемендәге дәүләт академик сынлы сәнгать институтының Казандагы филиалында белем бирә. Рәшит Гаимов филиалда укыту вакытын аеруча җылы искә ала, чөнки бу чакта ул Россиянең сәләтле рәссамнары, академиклары белән дә аралашып, үзе өчен тәҗрибә туплый. Ул белем биргән берничә буын яшьләр бүген үзләре дә мәгълүм иҗатчылар инде. «Мин Казанның Г.Ибраһимов исемендәге 17 нче татар гимназиясендә сынлы сәнгать һәм сызым дәресләрен укыту чорымда татар җәмгыятенең алдынгы шәхесләре булып китәрлек милли кадрлар тәрбияләүгә зур өлеш керттем», – ди педагог. Хәзерге вакытта улы Самат та югары белем ала, компьютер өлкәсендә зур уңышларга ирешергә тели.

Рәссам җирле дәрәҗәдәге, республикакүләм һәм Бөтенроссия күргәзмәләрендә актив катнаша. 2019 елны «Арт-география» халыкара проектында, 2020 елда Яр Чаллыда оештырылган «Югары басма» халыкара күргәзмәсендә әсәрләре куела. 2005 елда Мәскәүдә узган «Җиңү» халыкара күргәзмәсендә Татарстаннан бердәнбер рәссам була. 2005 елны Казанга 1000 ел тулу бәйрәме уңаеннан оештырылган күргәзмәдәге хезмәтләрен Казан, Мәскәү, Санкт-Петербург тамашачылары карый. 2007 елда Экслибрис буенча II Бөтенроссия күргәзмәсендә, 2011 елда «Зур Идел» күмәк күргәзмәсендә катнаша.

Аның әсәрләре Татарстан Республикасы сынлы сәнгать дәүләт музеенда, «Казан арты» Арча тарих-этнография музеенда, Вологда өлкәсе картина галереясы, Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгында, Әлмәт, Яшел Үзән сынлы сәнгать галереяларында, Баулы, Азнакай, Лениногорск, Бакчасарай төбәк өйрәнү музейларында һ.б. саклана. Р.Гаимовның хезмәтләре АКШ, Франция, Германия, Чехия шәхси тупланмаларында да бар. «Гомумән, Татарстан һәм Россиянең унике каласындагы унбиш галерея һәм музейларда йөз сиксән дүрт хезмәтем тупланды инде», – дип җөпли әңгәмәдәшем. Рәссамның шәхси күргәзмәләре 1988, 2002, 2011, 2016 елларда – Казанда, ә 2021 елда Азнакай туган якны өйрәнү музеенда һәм Яр Чаллы картина галереясында ачылган.

2019 елны Р.Гаимов Татарстан Мәдәният министрлыгының «Мәдәнияттәге казанышлары өчен» күкрәк билгесе белән бүләкләнгән. Быел исә аның иҗади эшләрен, җәмәгать эшчәнлеген, һәм педагогикага керткән тырышлыгын исәпкә алып, республиканың Рәссамнар берлеге тәкъдиме белән Рәшит Гаимовка «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» исеме бирелде.

«Быел «Арча батырлары» сериямне гравюра жанрында ясавымны дәвам итәм... – дип үз иҗади планнары белән уртаклашты Рәшит әфәнде әңгәмә ахырында. – Чөнки мин үземне Арча районы рәссамы дип тә саныйм әле. «Казан арты» музее белән дә якын хезмәттәшлектә. Газиз әнием Гарифә дә Арча районы кызы!»

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

Фотоларда Р.ГАИМОВ офортлары.

Планетаның үпкәсе

Кислород эшләп чыгарып, углекислый газны йотканга, күп кеше нәкъ менә урманны планетаның үпкәсе, дип саный. Чынлыкта исә безне кислород белән тәэмин итүдә һәм углеродны йотуда Бөтендөнья океанының әһәмияте күпкә зуррак. Агач һәм үсемлекләр барлык кислородның нибары 20 процентын җитештерә, калган 80 проценты белән исә безне океанда яшәүче фитопланктон тәэмин итә. Нәкъ менә фитопланктон һәм океанның тулаем экосистемасы эше нәтиҗәсендә Җир атмосферасы артык тиз җылынмый. Әмма кешелек, нефть суыртып, балык тотып һәм пластик белән пычратып, аны әкренләп һәлак итә. Океан углеродны йота һәм аны бик тирәндә саклый. Ул кеше эшчәнлеге нәтиҗәсендә һавага чыгарылган барлык углеродның 30 процентын үзенә ала. Әгәр Бөтендөнья океаны булмаса, планета бик тиз кайнарланыр һәм яшәү өчен яраксызга әйләнер иде. Диңгез суында углерод молекулалары башка химик кушылмаларга әйләнә яки фитопланктон өчен азык булып тора. Шул беркүзәнәкле суүсемнәр һәм цианобактерияләр ашаган молекулалар кислород һәм углеродка бүленә. Кислород суга кире кайтарыла, ә углерод фитопланктонда туплана. Әгәр океан углеродны йотудан һәм туплаудан туктаса, глобаль җылынуны берничек тә киметеп булмаячак. БМО мәгълүматлары буенча, дөнья океанының инде 40 проценты кеше гамәлләреннән зур зыян күргән. Һәр минут саен диңгезгә бер йөк машинасы пластик килеп эләгә, дип санала. Шулай дәвам итсә, 2050 елга океанда пластик балыктан күбрәк булачак. Китларны саклау фонды мәгълүматлары буенча, Кара диңгездә генә дә соңгы биш елда кеше китергән зыяннан 2,5 меңнән артык дельфин һәлак булган. БМОга ышансак, бүген эре балыклар популяциясенең 90 проценты тотылып бетә язган, мәрҗән рифларының 50 проценты юкка чыгарылган. Табигатькә ничек тә ярдәм итү максатыннан Россиянең Ерак Көнчыгыш һәм Себердән тыш бөтен территориясендә быелдан һәвәскәрләргә балыкны ятьмә белән тоту тыелган.

(“РБК”).

Үсемлек тә уйлый belә

Үсемлек орлыкларының үзенчәлекле “мие” бар икән, нәкъ менә ул аларга кайчан шытарга кирәклекне хәл итә. Флора серләрен өйрәнүче галимнәр ми режимында эшләүче күзәнәкләр төркемен тап булган. Алар үсемлекләрнең үз-үзен тотышын үзгәртергә һәм һава торышын фаразларга сәләтле. Әлеге “ми” һәр үсемлек тормышындагы төп карарны кабул итә – аңа кайчан үсәргә кирәклекне билгели, чөнки орлык вакытыннан алданрак шытса – аны кырау харап итәргә, соңгарак калса – иртәрәк чыккан туганнары басып китәргә мөмкин. Бирмингем университеты галимнәре үсемлек эмбрионындагы ми кебек эшләүче күзәнәкләр төркемен “арабидопсис” дип атаган. Әлеге күзәнәкләрнең кайберләре орлыкны йоклата, икенчеләре исә уята. Алар үзара гормоннар ярдәмендә аралаша. Мондый механизм безнең баш миендә дә бар, мәсәлән, ул бер урында басып торыргамы, әллә алга барыргамы кебек гади мәсьәләләрне хәл итә. Германиянең танылган урманчысы, “Агачларның яшерен тормышы” китабы авторы Питер Воллебен исә, үсемлекләр, куркыныч турында кисәтеп, бер-берсенә электр сигналлары җибәрә, дип раслый. Гомумән, менә нәрсә ачыклана: без моңа кадәр яшел дусларыбыз турында бик аз белгәнбез икән әле, үсемлекләр дөньясының никадәр катлаулы һәм кызыклы булуын хәзер генә әкренләп аңлый башлыйбыз.

(“Мир новостей”).

Каһәрле асылташ сере

Лондондагы Тауэрга килүчеләр королева Викториянең таҗына игътибар итми калмый. Ул “Кохинур” дигән зур бриллиант белән бизәлгән. Һиндиләр теленнән бу “нур тавы” дип тәрҗемә ителә. Аның авырлыгы 105 карат (21 грамм). Бу бриллиант турында китаплар язылган, фильмнар төшерелгән, әмма аның каһәрле тарихы тикшеренүчеләрне һаман да кызыктыра әле. Лондонда тарихчылар Уильям Далримпл һәм Анита Анандның чираттагы хезмәте дөнья күргән, анда асылташ хуҗаларына килгән бәхетсезлекләр турында сөйләнә. Риваятьләрдән күренгәнчә, бриллиант берничә гасыр буе Һиндстандагы Мальва ыруы раджаларыныкы булган, бәхетсезлекләр шул вакыттан башланган. Асылташ хуҗалары гел фаҗигале төстә дөнья куйган. 1739 елны Дәһлине фарсылар яулап алган, аның канаулары тулып кан аккан. Бөек Моголлар хәзинәсен, 700 фил, 4 мең дөя һәм 12 мең атка төяп, кәрван белән Иранга алып киткәннәр. “Кохинур” явыз Надир шаһ кулына килеп эләккән. Тиздән ул акылдан яза башлаган, улын үтертеп, күзләрен чокытып алган, тагын иллеләп вәзирен җәзалап үтерткән. Үзен дә озак яшәтмәгәннәр. Шуннан соң асылташ Әфганстандагы Кандагарга барып җиткән, андагы шаһ аны дивар ярыгына яшереп куйган. Әмма тиздән падишаһның битендә төзәлмәс җәрәхәтләр пәйда булган, шулар әрнүеннән ул җан тәслим кылган. Бриллиант Пенджаб махараджасы Ранджит Сингх кулына эләккән, ул асылташны гел үзе белән йөрткән. Тиз арада үлеп тә киткән. Аннары “Кохинур” өчен көрәштә тагын өч махараджа үтерелгән. Ун елдан соң бриллиант британиялеләр кулына эләккән, каһәре дә аларга күчкән – асылташны Лондонга алып кайтучы суднода ук холера башланган. 1851 елда ташны король зәркәнчеләре кырлап шомарткач, ул ике тапкырга җиңеләйгән, әмма искиткеч нәфисләнгән һәм үтә күренмәлегә әйләнгән. Гасырлар үтсә дә, “ләгънәт төшкән” бриллиант өчен көрәш туктамый. Һиндләр, пакыстанлылар, иранлылар, әфганнар – барысы да аны үзенеке саный һәм Лондоннан әлеге кыйммәтле реликвияне дәгъвалый. Мөгаен, аларның да үлем белән уйнайсы киләдер.

(“Goldengod.ru”).



